**Татарстан Республикасы**
**Биектау муниипаль районы**
**Суыксу төп гомуми белем бирү мәктәбе**

# *Өлкән булып үткән балачак.*

***(Тыл ветераннары, сугыш чоры балалары истәлекләре)***
***(1928-1945)***

**2019**

# Зарипов Абдулла Касыйм улы



Абдулла Касыйм улы Зарипов Дөбьяз районы Кондырлы авылында 1928 елның 20 нче маенда колхозчы гаиләсендә туган. Күрше Суыксу авылы мәктәбендә 1944 нче елда җиде класс тәмамлый.

Сугыш башланганда, 13 яшендә уку белән бергә, Суыксудан почта алып кайтып тарата торган була. Укый-яза белмәгән бабайларның улларының сугыштан язган хатларын укып, аларга җавап хатлары яза, аңар әби-бабайлар бик рәхмәтле булалар.

Язуы бик матур була Абдулла абыйның, әле хәзер дә язуын үрнәк итеп куярлык аның! Шул ук вакытта колхозда хисапчы хезмәтен дә башкара ул. “Кулдан килгәнчә, сугыш тизрәк туктасын дип, булдыра алганча эшләргә туры килде”,- ди Абдулла абый.

1943 нче елдан МТСта трактор бригадасында учётчик эшен башкара. 1944 нче елдан 1948 нче елга кадәр тракторчы була. 1948 нче елдан алып 1988 нче елга кадәр Уралда Кизел шахталарында забойщик, мастер-взрывник булып эшли. Абдулла абыйның шахтадагы эш стажы 40 ел.

Әтиләре, яше бик олы булгач, сугышка алынмый. 1943 нче елда авырып үлә. Әнисенең энесе Хайруллин Саттар сугышта һәлак була.

Абдулла абый тормыш иптәше белән бер ул, бер кыз тәрбияләп үстерәләр. Хатыны үлгәч, туган авылына кайтып, шушында яши Абдулла абый. Пенсионер Абдулла абыйның истәлекләре белән танышып, нинди тырыш, тәвәккәл кеше булган, дип уйлап та куясың.

Аның 1973, 1975, 1976, 1978 нче елларда алынган “Победитель социалистического соревнования” медальләре бар , тырышлыгы, намус белән эшләгәне, һәрвакыт алдынгы кеше булганы өчен, күмер промышленностенда күп еллар эшләгәне өчен бик күп Мактау грамоталары белән бүләкләнә. Аның “Ветеран Великой Отечественной войны”, “Ветеран труда” кенәгәләре дә бар.

Абдулла абыйга сәламәтлек, Җиребезгә тынычлык телибез!



***6 нчы сыйныф укучылары***
***Ганиева Рузилә, Хакимова Илүзә.***
***2014 ел.***

**инә Бәдриевна**



Сугыш беткәнгә дә 69 ел узып бара, әмма аның дәһшәте – көл булган шәһәр - авыллар өстендә, яу кырыннан кайтмый калган ир- егетләр , әти- бабалар каберлегендә. Аның сары сагышы әтисезләр йөзендә. Алар сугыш дигән ачы хәсрәтнең фаҗигасен туганнан ук тоеп, үз күзләре белән күреп, ачлык - ялангачлыкның ни икәнен татып үскән. Алар утлы елларда туган балалар. Шуңа күрә сабыр, нык алар. Шуларның берсе - Батталова Әминә Бәдриевна. 1933 нче елгы, Чәмәктә туган. Чәмәктә колхозда эшләгән. 8 класс белем алган. Тормыш иптәше белән горурланырлык 3 бала тәрбиләп үстергәннәр. Барысы да үз юлларын тапканнар. Бик яшьли тол калган Әминә апа. Бүгенге көндә хезмәт ветераны.

Сугыш башланганын әнисе әйткән, әтисе сугышка кадәр үк үлгән, абыйлары чыгып киткәч елап калганын бүгенгедәй хәтерли Әминә апа.

Ул елларның бөтен михнәтен, газабын, авырлыгын үз башына төшкән кеше генә аңлый кадыр, билгеле. “Ул вакыттагы кичерешләрне сөйләп бетерерлек түгел иде. Бар да елый, бар да кайгыра”- дип искә ала ул көннәрне. Билгесезлек чорнап ала аларны. Ил өстенә төшкән афәтне бөтен ил күләмендә күтәрергә кирәк була. Сугыш башлангач юклык тагын да арта. Авылдагы атларны алып китәләр. Колхоздагы эшләр кул хезмәте белән башкарыла, үгезләр, сыерларны ат урынына җигәләр. “Уфалла арбасы” белән симәнә ташыйлар, печән чабалар, урак уралар. Олылар белән берлектә балалар да шул ук эшләрне эшлиләр. Күкәри белән тукланалар, үлән ашлары ашыйлар. Фронт өчен кулдан килгәннең барсын да эшлиләр.

Ниһаять сугыш бетә. Авыл халкы бәйрәм итә. Һәр солдатны куанып каршы алалар. Әминә апаның ике абыйсы да исән-сау әйләнеп кайталар. Сугыш бетте дип кенә хәл җиңеләйми. Сугыштан соңгы чорлар да авыр була. 16 яше тулгач Әминә апаны Лаеш урманы кисәргә җибәрәләр. Ябь-яшь кызлар агачны кул белән кискәннәр. Агачлар берсе өстенә икенчесе ауып, алырга авырлаша торган була. Шул вакытта ирләр килеп, бер агачны икенчесе белән бәрдереп төшерә торган булганнар. Ул агачларны хатын-кызлар бутаганнар, кирәкле озынлыкка куеп кискәләгәннәр.



Шулай да зарланырга яратмый Әминә апа. Язмыш күпме генә хәсрәт китереп, күпме генә изсә-сытса да, яшәү ямен, тормыш мәгънәсен югалтмаган. Бүгенге көндә аллаһы тагәлә беркемгә дә сугышлар күрсәтмәсен, балалар ятим үсмәсеннәр, әти-әниләре белән яшәсеннәр дигән теләктә яши.

**Бикмуллина Энҗе**
**Хайруллина Гөлинә**
**5 нче сыйныф**

## Вәлиева Рәшидә Хәнәфи кызы



Вәлиева Рәшидә Хәнәфиевна Әтнә районы, Ташчишмә авылында 1933 елның 12 ноябрендә туа. Ташчишмә авылы мәктәбендә җиде еллык белем ала. Гомере буе колхозда эшләгән, урман кисkәннәр. Сугыш башланганда сигез яшь булган. Сугыш елларында урман кискәннәр, фермада сыер сауганнар. Өч абыйсы сугышка киткән. 1923 елгы апасы сугышта һәлак булган. Рашидә апа гомер буе штукатур-маляр булып эшли.

Бик күп мактау грамоталарына ия: ”Рабочая строительства Актюбинской областной госплемстанции за долгую, безупречную работу”, “В честь праздника работников агропромышленности комплекса” “Штукатур-маляр”, “За высокие показатели в выполнении планов и социалистических обязательств, активное участие в реализации строительной программы” һ. б.

## Фатыйхов Рашид Фатыйх улы



Фатыйхов Рашид Фатыйхович 1936 елның 29 октябрендә Дөбьяз районының Суксу авылында туа. Суыксу мәктәбендә 10 сыйныф белем ала. Ташучы булып, фермада төрле эшләр башкарган. Сугыш башланганда 5 яшь кенә булган була. Сугыш чорында эшләмәгән, чөнки кечкенә булган.1952 елда эшли башлаган. Сугышка әтисе һәм өч абыйсы киткән. Әтисе әйләнеп кайткан. Абыйлары:Фатыйхов Насыйх, Шакиров Касыйм,

Садыйков Хабибрахман. Сугыш чоры ветераны. Үзе эшләгән дәвердә мактау грамоталары белән бүләкләнгән, ләкин алар бүгенге көнгә кадәр сакланмаганнар (янганнар).

**Ардашова Гөлинә, 11 сыйныф**

# Газизова Хәлидә Минебаян кызы



Т

Тормышның үз законы бар: еш кына яхшылыклар онытыла, ә авырлык, кайгы – хәсрәт хәтердә мәңгегә уелып кала. Шуның өчен дә халкым чиксез булып тоелган дәһшәтле сугыш көннәрен бүгенгедәй хәтерли. Җирдә мәңгелек тынычлык булсын өчен, миллионнар һәлак булган бит. Халидә апага да югалтулар, ятимлек, әче күз яшьләрен күрергә туры килә. Ул 11 яшендә әтисез кала.

Газизова Хәлидә Минебаян кызы 1931 нче елның 1 нче маенда Башкортстанның Ниякин районы Качаган авылында дөньяга килә. Гаиләдә 5 бала тәрбияләнеп үсәләр. Хәлидә апа 7 классны бетерә. Сугыш башлана. Сугышның беренче көненнән үк әтисен, Минебаян абыйны сугышка озаталар. Әнисе 5 бала белән ялгыз кала. Аларны ашатырга, киендерергә кирәк. Әнисе белән беррәттән Хәлидә апа да нинди генә эшләр башкармый. Җирен дә тормалый, игенен дә чәчә, урагын да ура, урманын да кисә. Көтмәгәндә Халидә апаларның өенә кара кайгы килә. Әтисе Минебаян абый сугыш кырында үлеп кала. Әнисе 5 бала белән ялгызы кала. Тормышны дәвам итәргә кирәк. Хәлидә апа бер эштән дә курыкмый. Нинди генә эшкә тотынса да, югалып калмый. Сугыштан соң авылда сөт җыючы, учетчик булып эшли. Бервакыт укырга теләге туа. 1949 нчы елны Үзбекстанга китә. Анда барып урнашкач, кооператив техникумына укырга керә. Техникумны кызыл дипломга тәммамлый. 1954 нче елны Газизов Хәмид абый белән тормыш корып җибәрәләр. Акыллы, эшчән 3 ир бала тәрбияләп үстерәләр: Рафаэль, Равил, Рамил. Балаларының өчесе дә югары белемле. Барысы да уку йортларын кызыл димломга тәмамлаганнар.

Хәлидә апа 47 ел буе кибеттә җитәкче булып эшли. Эшләү дәверендә бик күп төрле мактау кәгазьләре, "Фидакарь хезмәте өчен" медале, хезмәт ветераны ордены белән бүләкләнә. Кайгы җиле Халидә апаның бусагасыннан үтеп керә. 2004 нче елны тормыш иптәше Хәмид абый авырып үлеп китә. Язмыш Халидә апаны төрле яктан сынаса да, ул үзендә Ходайдан көч, сабырлык сорап, бүгенге матур, мул тормыштан ямь табып яши.

**Абдурахманова Эльвина**
**8 нче сыйныф укучысы**

## Галиуллина Кәүсәрия Габдрахман кызы

1936 нчы елның 2 нче гыйнварында Биектау районы Кындырлы авылында туа. Суыксу мәктәбендә 7 класс белем ала. Сугыш башланган вакытта яшь кызчыкка 5 яшь була. 8 яшь вакытта урак ура башлый. Шулай ук әниләренә ашарга пешереп илтә. Ашарга ул вакытта үлән, кычыткан ашы була. Шуңа да риза булып бар көчләрен куеп эшлиләр ул вакытта. Нишләсеннәр, сайланып утырыр чак түгел.

Тылдагы хезмәтчәннәрнең җиңүне якынайтуга бик күп хезмәтләре керә. Шулар арасында Кәүсәрия апа да була.

Кәүсәрия апаның әтисе 1941 нче елның көзендә китә. Шул ук вакыта әтисенең абыйсы да алына. Алар икесе дә һәлак була. Аңа ятимлек ачысы да татырга туры килә.

Үз гомерендә Кәүсәрия апа үлчәүдә, 8 ел фуражир булып эшләгән, бозау караган, көтү көткән, сыер сауган, 12 ел сөт җыйган.

Тормыш иптәше белән 2 кыз, 1 малай тәрбиләп үстергәннәр. “Инде авыр еллар артта калды” - дип, бүгенге көнгә куанып, булганына шөкер итеп кызы тәрбиясендә бәхетле гомер кичерә ул. Һәр укыган намазында илләргә иминлек, кешеләргә саулык теләп дога кыла.

**Усманов Рүзәл**
**8 сыйныф укучысы**

# Гәлимҗанова Филсия Нигъмәтҗанов кызы

Филсия апа- сугыш чоры баласы. Ул 1941 нче елның 29 нчы июлендә дөньяга килә. Зур өметләр белән тудырган баласын әнисе шундый дәһшәтле сугыш башланганның икенче аенда тудырырмын дип башына да китермәгәндер. Яңа туган сабыйларга әниләренең җылы кочагында иркәләнеп утырырга язмаган. Әниләре аларны күтәреп басуга алып барганнар.Көне буе басуда ятканнар нарасыйлар. Әниләре иртә таңнан кичкә кадәр бил бөгеп урак урганнар, чиләк-көянтә күтәреп ашлыкны амбарга ташыганнар.

Филсия апаның әтисе сугышка 1941 нче елны китә, озак сугыша алмый, ашказаны авыртып аны кире кайтаралар.Шул авыру белән озак азаплана әтисе, авыруны җиңеп булмый. Сугыш бетеп 3 ел узгач вафат була.

Әнисе 4 бала белән тол кала. Төшенкелеккә бирелми, 4 баласын үстереп кеше итәр өчен алны-ялны белми колхозда хезмәт куя.

Филсия апа үзе дә бик тырыш, эшчән бала булып үсеп җитә. Әнисе сөйләгәннәрдән сугыш беткәнен бик шатланып, авылга кайткан һәр сугышчыны каршы алганнар. Бәрәңге яфраклары, кузгалаклар ашаганнары, ачлыктан тилмергәнлекләре дә онытылган.

Филсия апа 4 класс белем ала. Шул белем белән чикләнергә туры килә. Башка укый алмый. Шуннан бирле гел хезмәттә була. Аның гомуми эш стажы 40 ел. Ул озак еллар дәвамында Чәмәк сарык фермасында эшли, колхоздагы бер эштән дә тайчынмый.Тормыш иптәше Гыйният абый белән 2 кыз, 1 малай үстерәләр. Әнисе шикелле ул да яшьли тол кала. Ялгызы гомер кичерә. Балалары аны ташламый, бик еш кайтып хәлен белеп торалар. Аның хәзер 6 оныгы, 2 оныкчыгы бар.

Яшь буынга теләкләре: наркоманнар булмаска, аракы эчмәскә, тәмәке тартмаска.Сәламәт булганда гына яшәве күңелле ди ул. Чөнки үзе гомер буе сәламәтлеккә туеп яшәми. Шулай да бервакытта да зарланып, өметсезлеккә бирелми, булганына риза булып көн күрә.

**Ахметханов Әнис, Кадыров Илсаф**
**5 нче сыйныф укучылары**

# Дәминов Әдһәм Мифтахович

Бөек Ватан сугышы хатирәләре анда катнашучы фронтовиклар һәм тыл батырлары күңелендә генә сакланмый. Еллар үтү белән алар шушы Җиңүне яулашкан солдатларның уллары һәм кызлары күңеленә дә күчә. Аларның берсе Әдһәм абый.



1940 нчы елның 15 нче гыйнварында Дөбъяз районы Кече Рәс авылында туган. Авылда торган, Кече Рәс 7 еллык мәктәбендә 6 класс укыган.
Сугышта әтисе Мифтах Исмәгыйль абыйсы, катнашкан. Балалары Гөлфия, Әгъзәм, Талия. Хезмәт стажы 42 ел. Гомер буе тракторда эшләгән. Ул сөйләгән хәтирәләр менә нидән гыйбарәт.

"Сугыш башланганын әниләр елаганнан белдек. Сугыш вакытында бик күп күрдек. Ачлык-ялангачлык бала вакытта үзәккә үтте. Ашарга черек бәрәңге, ат кузгалагы, чыпчык кузгалагы. Шулар гына исән калдырды безне.

Әниләр алны-ялны белмичә көннәр буе колхоз эшеннән кайтып кермәде. Сугышка оекбаш, бияләйләр бәйләп җибәрделәр.

Җиңү турында урамда уйнаганда, сугыштан кайткан кешеләрне күргәч белдек. Сугыш бетте. Аллага шөкер. Ләкин әле аның нужасы 60 нчы елларга кадәр дәвам итте. Сугыштан соң барлык кешеләр кебек эшләдек авырлыкларга бирешмәскә тырыштык.

Инде, Ходаем, безнең балаларыбыз, без күргәннәрне күрмәсеннәр. Оныкларыбыз яхшы мәктәпләрнең кадерен белеп, укытучыларын хөрмәт итеп яшәсеннәр иде. Дөньялар тыныч, имин булсын, барысы да сау-сәламәт булсыннар".

# Зәйниева Әлфия Ярулловна



Әдһәм абыйның тормыш иптәше Әлфия апа 1942 нче елның 5 августында Кече Рәс авылында туган. Кече Рәс мәктәбендә 7 класс белем ала. Аның хезмәт стажы 43 ел. Соңгы вакытта колхозда сыер савучы булып эшли. Хезмәт ветераны.
"Сугыш безнең сабый йөрәкләребезгә куркыныч янаган һәм безнең балачак тормышыбызны ач, ялангач, бәхетсез иткән көн дип башлады ул сүзен. Үзебезне беләә башлаганнан бирле иписез, ач булдык. Ярый әле Аллаһы Тәгалә безне ачтан үтермәс өчен ризыгын бирде: язга чыгу белән, пычракка батып, черек бәрәңге җыеп алып кайта идек. Җәй көне кузгалак, кәҗә сакалы, кычыткан, балтырган, акбаш җыеп ашый идек. Менә безне үлемнән шулар саклап калды. Сугыштан соң бик авыр яшәдек, дип сөйли. Өскә киярге юньле кием - салым, ашыйм дисәң ашарга булмады".

Ничек кенә авыр булмасын, сынатмаган Әлфия апа. Кая җибәрсәләр дә, нинди генә эш кушсалар да эшләгән. Шуңа күрә хәзер рәхәтләнеп яши, пенсияне вакытында ала. Яшь буынга теләкләре: Без күргәнне балаларыбыз күрмәсеннәр. Булганына шөкер итеп, куанып, сау-сәламәт яшәсеннәр.



**Низамиев Булат**
**7 сыйныф**

# Әхмәтҗанов Әхмәтхан Закирҗан улы




Әхмәтҗанов Әхмәтхан Закирҗан улы 1930 елның 2 нче июлендә Дөбьяз районы Кондырлы авылында туган. Кондырлы мәктәбендә дүрт класс укыган.

Сугыш башланганда Әхмәтхан абыйга унбер яшь булган. “Бөтен олылар эшен эшләдек. Үгезләр җиктек, көлтә ташыдык. Спиртзаводка үгезләр җигеп барабыз, аннан ипи ташыйбыз. Атлар урынына үгезләр җигәргә туры килде. Өскә кияргә юньле кием-салым, ашыйм дисәң ашарга юк. Ничек кенә авыр булмасын, сынатмадым. Кая җибәрсәләр дә, нинди генә эш кушсалар да эшләдем. Моннан соң балаларга, оныкларга ул язмышларны күрергә язмасын. Илләр тыныч, күкләребез аяз, йөзләребез шат булсын. Ил башлыкларына сәламәтлек, миһербан, шәфкать бирсен”, - ди Әхмәтхан абый.

Әхмәтхан абыйның бертуганнары Шакирҗан һәм Газизҗан абыйлар да Бөек Ватан сугышында булганнар. Шакирҗан абый сугышның ачысын татып, туган иленә исән-сау әйләнеп кайта алган. Газизҗан туганы кайта алмаган... “Солдатлар өйрәтә торган җирдә аларны ябып торганнар, бүрәнә ташытканнар, ашатмыйча ачтан үтергәннәр...”

Армиядә Венгриянең башкаласы булган Будапешт шәһәрендә хезмәт иткән ул.

Чувашилендә тракторга укыганнан соң, шунда ук 1947 елда тракторчы булып эшли башлаган, үз авылында да эшләгән. “Тракторда гомер буе, пенсиягә чыккач та эшләдем әле”, - ди Әхмәтхан абый. Аның кыр эшләрендәге намуслы хезмәте, уңышлары өчен бирелгән Мактау грамоталары да санап бетергесез.



Шундый тырыш, тәвәккәл, максатчан Әхмәтхан абыйга озын гомер, саулык –сәламәтлек телибез.

***6 нчы сыйныф укучылары***
***Ганиева Рузилә, Хакимова Илүзә.***
***2014 ел.***

# Әхмәтҗанов Сәлихҗан Закирҗанович



“1941 елның 22 июне безнең сабый йөрәкләребезгә куркыныч янаган һәм безнең балачак тормышыбызны ач, ялангач, бәхетсез иткән көн.

Мин 1929 нчы елның 29 нчы маенда дөньяга килгәнмен. Сугыш вакытында Кындырлы авылында торган. 4 класс белем алдым. Аны уку дип әйтеп тә булмый инде. Эт шомыртыннан, кырымнан ясаган каралар, каурый ручкалар, иске китап битеннән кисеп ясаган дәфтәрләр. Колхозда ат белән сука сукалаганнар.

Сугыш башланганын басуда ат белән сукалаганда белдек. Эшләдек тә эшләдек. Ике абый сугышка китте. Сугыш вакытын кайгы – хәсрәт белән авыштырдык. Үгез җигеп, нәрәткә барып, көне-төне эшләп сугыш авырлыгын җиңгәнбездер. Өметсезлеккә бирелергә вакыт булмады. Бер кеше дә булышмады, үзем тырыштым, әти-әни дә картлар иде. Ат белән сука сукаладым, тырмаладым, чәү машинасы белән чәчү чәчтем, лабогрейка белән урак урдым. Җир чыгуга черек бәрәңге җыеп ашадык. Ашка ат кузгалагы, кычыткан, бәрәңге сабагын салып пешердек. Начар шартларда яшәдек, мичкә ягарга утын юк, өйләр салкын. Сугышчыларга бәрәңгеләр киптереп җибәрә идек. Бабай солдатларга агач олтанлы ботинкалар ясап җибәрә иде. Сугыш беткәч Шакирҗан абый кайтты, Газизҗанабый хәбәрсез югалды. Сугыш бетте дип басуга килеп әйттеләр. Бабайлар басуда биеп йөрделәр. Мәктәптә дә җырлап- биегәннәр.

Менә 1945 нче елда сугыш бетте, Аллага шөкер. Ләкин әле аның нужасы 60 нчы елларга кадәр дәвам итте.

1958 нче елдан комбайнда эшли башладым. Хезмәт хакын таяклап, сутыйлап яза иделәр (бер тиенсезгә). Соңгы вакытта кочегар булып эшләдем. Хезмәт стажым - 50 ел.

Инде, Ходаем, безнең балаларыбыз, без күргәннәрне күрмәсеннәр иде. Оныкларыбыз яхшы мәктәпләрнең кадерен белеп, укытучыларын хөрмәт итеп яшәсеннәр иде. Аларга бәхетләр, тәүфыйклар телим”.



Сәлихҗан абый тормыш иптәше белән бер кыз, бер малай тәрбияләп үстергәннәр. Хәзерге көндә ул кызы белән яшәп ята. Тыл ветераны, хезмәт ветераны. Медальләре: “За доблестный труд в Великой Отечественной войне” 1941-1945 г.г., “За доблестный труд ознаменование 100-летия со дня рождения Владимира Ильича Ленина” 2 апреля 1970 года., “50 лет победы в Великой Отечественной войне 1941-1945 г.г.” 22 марта 1995 года., “60 лет победы в Великой Отечественной войне 1941-1945 г.г.” 5 марта 2009 г., “65 лет победы в Великой Отечественной войне 1941-1945 г.г.” 20 марта 2010 года, “55 лет победы в Великой Отечественной войне 1941-1945 г.г. 9 мая 2000 года., “Ударник девятой пятилетки 30.01.1976 г.”, “Победитель социалистического соревнования 1973 года” 21.01.1974 года., “Ударник коммунистического труда” 2 марта 1981 года.

# Әхмәтханов Әгъләм Һадиулла улы

Әхмәтханов Әгъләм Һадиулла улы 1941 нче елның 4 июнендә Биектау районы Чәмәк авылында Һадиулла һәм Бибиасиянең 4 нче баласы булып дөньяга килә. Аның белеме 7 ел. 4 класс-Чәмәк авылында, 3 ел Суксуда укыган.7 ел укыганнан соң гел эштә, хезмәттә булган. Уку белән беррәттән ат белән төрле эшләрдә эшләгән. Аннан соң Пичищедан ат белән симәнә орлыгы ташыганнар. Шуннан соң инде лаеклы ялга чыкканчы колхозда фермада ат җигүче дә, бозау-үгезләр симертүдә эшләгән. Кышын фермада, җәен сыер көтүендә көтүче булган. Лаеклы ялга чыкканнан соң да 10 елдан артык колхозда эшләвен дәва итә дәү әтием. Гаилә подряды булып Чәмәк авылы фермасында үгезләр симертәләр. Ул вакытта бөтенесе дә кул хезмәте белән эшләнгән. Фермадагы тиресне дә кул белән түгәләр. Онны күтәреп ташыганнар. Хәтта бозауларга, үгезләргә ашату өчен дә люцернаны кул чалгысы белән чабып, үзләре төяп ташыганнар. Бу бик авыр хезмәт булган.

Шундый авыр хезмәтләре өчен колхоз, район грамоталары белән бүләкләнгән, ләкин Хезмәт ветераны дигән исем (удостоверение) бирелмәгән. Моңа дәү әтиемнең йөрәге бик авырта. “Гомерем буе эшләдем, ләкин Хезмәт ветераны була алмадым” - ди дәү әтием.

Хезмәт стажы 50 елдан артык. Сугыш башланганда дәү әтием 18 көнлек сабый булган. Бабаем (Һадиулла) 3 кызын һәм 4 нчесе дәү әтием 4 баланы калдырып, сугышның 1 нче көннәреннән үк сугышка китә.

Бибиасия сөйләгәннәрдән (дәү әтиемнең әнисе): беркөнне Галләм абый ясак җыярга кергән. Нәрсәң бар шуны бир дигән.

- Әнә, өйдә 4 капчыкның авызын каплап куйдым, ал шуларны,- дигән. Галләм абый кергәч, ачлы-туклы 4 баланы күргән һәм кире борылып чыгып киткән. Сугыш вакытында кикәрине киптереп, уып ашаганнар. Авылда дуңгызлар асраганнар. Дуңгызларга зур казанда үлән белән буталган бәрәңге кабыклары пешергәннәр. Шушы ризыкны урлап-урлап кына ашаганнар, ә балаларга кычыткан, юа, кузгалак җыеп, пешереп ашаганнар, шуларның суларын эчергәннәр.

Кигән киемнәре киндер, мең ямаулы күлмәкләр булган.

Дәү әтиемнең әтисе (Һадиулла) сугыштан бер кулын эздереп кайта. Сугыш беткәч ул госпитальдә дәвалана. Аның исән икәнен дә белмиләр, үлү хәбәре дә булмый. Ул гарипләнеп, төшенкелеккә бирелеп кайта. Гаиләсе янына кайткач, авыртуы бераз басылгандай була. Шуннан соң ул сул кул белән эшләргә өйрәнә. Сул кул белән себерке тотып себерә, хәтта бер кул белән ат җигә.

Сугыштан соң тагын бер кыз һәм бер малай алып кайталар. Бүгенге көндә бу 6 бала барысы да исән – саулар: 4 кыз һәм 2 малай.

Дәү әтием һәм дәү әнием үзләренең 4 малае булган. 1 се кечкенә вакытта ук үлгән. Ә 3 малай Әдһәм, Наил, Әнис бүгенге көндә үз тормышларын корып яшиләр.

Әдһәм (ул минем әтием) гаиләбез Суыксу авылында яши, ә 2 малай икесе дә Биектау авылында үз гаиләләре белән яшиләр.

**Ахметханов Әнис**
**5 нче сыйныф**


## Закиров Шамил Шакирҗан улы



Закиров Шамил Шакирҗан улы 1929 нчы елның 11 декабрендә элеккеге Дөбъяз районы, Кече Рәс авылында туган. Кече Рәс җидееллык мәктәбендә өч класс тәмамлап, башлангыч белем алган. Мәктәптә укыганда ук колхоз эшендә эшли башлаган. Мәктәптән кайткач, укытучылар коллективы белән, колхозның борчак басуында бер көн калмый борчак чапканнар.

1941 елның 22 нче июнендә сугыш башланган. Әтисе 25 нче августта сугышка киткән. Ул вакытта Шамил абыйга 11 яшь тулган була. Ә әнисенә 34 яшь була.


"Шулай итеп без әнигә 3 бала җыелып калдык. Энем Камилгә- 7 яшь, сеңлем Филсинәгә 3 яшь иде. Сугыш вакытында мин барлык хатын-кызлар белән печән чаптым, кибән куйдым, салам эскертләдем. Азрак үсә төшкәч,минем күңелем агач эшенә тартыла башлады. Иң элек балта остасы Шәйдулла бабайга ярдәмче итеп куйдылар. Шунда инде мин чын-чынлап балта эшенә өйрәндем. Ат арбалары, ат чаналары, ат көпчәкләре, кул тырмалары ясадык. 1943 елда Шәйдулла бабай эшен миңа тапшырды. Шуннан барлык балта эшләре минем җилкәдә булды",- дип искә ала Шамил абый. Әле алай гына түгел, чәчү чәчкәндә , барлык симәнә ташулар да, яз көне кул чаналары белән фермага атларга, сыерларга коедан су чыгарып су ташу да, алар өстендә булган. Кышкы салкын буранн
казып, салам төяп
тә торганнар.



"Сугышка безнең өйдән бер әти генә китте. Сугы
вакытында без бала булып исәпләнгәнлектән, безгә кәгаз
бирмәделәр. Сугыштан соң да, бер дә тик тора белмәде
бер көн калмыйча эшләдек. Бер дә эшләмәгән эш калмад
Аллага шөкер ходай сәламәтлекне бирде. Шуның өче
миңа „Хезмәт ветераны" дигән исем бирделәр ",- д
Шамил абый. Яшь буынга теләкләре: "Җир йөзе тыныч бул
сын, беркем дә авырмасын"

**4 нче һәм 7 нче сыйныф укучылары**
**Низамиев Булат һәм Ришат.**

## Закирова Марзия Васыйл кызы



Василова Марзия 1938 нче елның 20 нче июнендә Дөбъяз районы Кече Рәс авылында туган. Шул авылда җидееллык мәктәптә 7 класс белем алган. 1953 нче елны яшелчә бригадасында эшли башлаган. 1954 нче елның май аеннан 1962 нче елга кадәр шушы ук колхозда сыер савучы булып эшләгән.

"Тугыз ел бер көн ялсыз, бер көн калмый эшләдем. Ундүрт баш сыерны кул белән саудым, фермаларда салкын суларны үзебез җылыта идек. Тиресләрне дә үзебез төядек. Тугыз көнгә бер тапкыр фермада дежур тордык. Төне буе караңгы фермаларда сыерлар бозаулатып йөрдек",- дип сөйли ул еллар турында Марзия апа.

Шуннан соң 1962 нче елда шушы авылның егете белән Иркутск өлкәсенә " Братск ГЭС"ын төзергә киткән. Анда 27 ел тимер юллар салган. Ике малай тәрбияләп үстергәннәр. Анда да ялсыз армый-талмый эшләргә туры килгән Марзия апага.

Эшләгәннәрен искә алып , хөкүмәтебез " Хезмәт ветераны" медале белән бүләкләгән.

Марзия апаның әтисе Галәвиев Васил 1941 елның июль аенда сугышка киткән. Ул вакытта Марзия апага өч яшь була. "Сугыш вакытындагы авырлыкларны әйтеп бетереп булмый. Әнинең ике бертуган абыйлары була.Әти белән алар да сугышка китәләр. Барысы да сугыш кырында ятып калалар. Мин әтине бөтенләй белмим",-ди Марзия апа. 2009 нчы елны Марзия апа туган авылына әйләнеп кайта. "Хәзерге көндә Аллага шөкер, тамак тук, өс бөтен, безгә , авырлыклар күргән балаларга , җәннәт менә шул инде",- ди Марзия апа.

**4 нче һәм 7 нче сыйныф укучылары**
**Низамиев Булат һәм Ришат.**

# Закирова Гадилә Сөнгать кызы



Минем дәү әнием, Закирова Гадилә Сөнгать кызы 1941 нче елның 6 нчы гыйнварында, Биектау районының Мәмдәл авылында туа. Сугыш башланганда аңа нибары 6 ай була, әтисе, Сөнгать сугышка китә, өйдә 7 бала кала. Иң олы туганнарына 13 яшь була. Әтисен дәү әни хәтерләми, аның фотосурәте дә булмады дип әйтә. Сугыш афәте аларны әтисез калдыра. Дәүәни сөйләгәннәр буенча, әтисе аларга сугыш кырыннан җидесенә җиде төрле хат яза торган булган. Еллар узган, сугыш тәмамланган, 1945 елның язын, кечкенә булуына карамастан, ул бик яхшы хәтерли. “Бу көн иң олы бәйрәм иде” - дип искә ала.

1949 елда Мәмдәл урта мәктәбенә укырга керә, анда 10 класс белем алганнан соң, Казан медицина көллиятенә урнаша,бу уку йортын тәмамлап, Биектау районы Суыксу авылына шәфкать туташы булып эшкә урнаша. Бер ел бу урында хезмәт куйгач, ул Казан педагогия институтына биология-химия факультетына укырга керә. Биш ел укыганнан соң, тагын да Суыксу авылының урта мәктәбенә биология һәм химия укытучысы булып урнаша. 28 ел эшләгәннән соң, безне-оныкларын тәрбияләргә, лаеклы ялга чыга.

Эшләү дәверендә аның алган бүләкләре : 1990 елда - “Отличник народного просвещения” значогы, 1990 елда Татарстан Республикасы Мәгариф Министрлыгы грамотасы, бик күп район мәгариф бүлеге грамоталары.

Дәүәниемнең хезмәт ветераны дигән мактау кәгазе бар ,бу яхшы укытучылар өчен генә бирелә торган булган.

**Суыксу гомуми урта белем мәктәбе укучысы**
**Закирова Энҗе**

# Закирова Рушания Исмәгыйль кызы



Бөек Ватан сугышы. Бу сугыш хакында уйланулар каршылыклы хисләр кузгата. Бөек Җиңү - ул халкыбызның горурлыгы, сагышы. Йөрәк әрнүе. Әрнү – чөнки һәлак булган каһарманнарны беркайчанда кире кайтарып булмый. Горурлану хисе – чөнки алар дошман алдында тез чүкмәгәннәр, кешелек тарихындагы иң каты, иң газаплы сугышта чын фидакарьлек күрсәтеп җиңеп чыкканнар дип, сөйли дәү әнием Рушания Исмәгыйль

1936 нчы елның 3 июнендә Биектау районы Суыксу авылында Сәгадәт дәү әнием белән Исмәгыйль дәү әтиемнең икенче балалары булып дөньяга килә. Гаиләдә 3 бала тәрбияләнеп үсәләр.

Матур гына гомер кичергәндә, көтмәгәндә кайгы килә. Сугыш башлана. Карт дәү этим Исмәгыйльне сугышның беренче көненнән үк сугышка озаталар. Ул вакытта дәү әниемә 4 яшь була. Карт Дәү әнием Сәгадәт берсеннән берсе кечкенә 3 баласы белән ялгыз кала. Тормыш авырлаша. Балаларны ашатырга, киендерегә кирәк. Көтмәгәндә Дәү әниләргә дәү әти хәбәрсез югалган дигән хат килеп төшә. Дәү әнием Рушания әтисез кала. Мәктәптә 7 класс белем алганнан соң карт дәү әнигә булышырга кирәк дип, колхозга эшкә керә. Хезмәт юлын фермада сыер савучы булып башлап җибәрә. Әвенендә дә эшләгән, печәнен дә чапкан. Нинди генә эшкә тотынса да, җиренә җиткереп эшләгән. Язмыш дәү әниемне бер – бер артлы тагын сыный башлый. Бертуган абыйсын югалта. Ул бик яшьли авырып үлеп китә. Дәү әнием Рушания берничә ел колхозда эшләгәннән соң, Казанга заводка эшкә китә. Уңган, эш сөючән, тырыш кызны күреп, Ташсу авылына кибеткә сатуч



42 ел шул эшенә тугры булып эшли. Эшләү дәверендә бик күп мактау кәгазьләре, медальләр белән бүләкләнә. Дәү әтием, Булат белән очрашып, тормыш корып җибәрәләр. Ике бала тәрбияләп үстерәләр. Көтмәгәндә энесен, Юныс абыйны да югалта. Дәү әнием шул хәсрәтләрнең барысын да җиңеп, тормыштан ямь табып яши белә ул. Аның шундый көчле рухлы, сабыр, акыллы булуы белән без, балалары, оныклары горурланабыз. Аңа дәү этием белән тигез матур тормыш, сәламәтлек, бәхетле картлык теләп калам.

**Закиров Зөфәр Айрат улы**

**9 нчы сыйныф укучысы**

**Зиганшин Илдус Зиганша улы**



Зиганшин Илдус абый 1930 нчы елда Татарстан Республикасы Биектау районы Суыксу авылында туган. Кечкенәдән тырыш, белемгә омтылучан була ул. 7 нче сыйныфны тәмамлагач, тагын 3 ел Дөбъяз мәктәбендә укуын дәвам иттерә.

Илдус абый гел җаваплы эшләрдә эшләгән, китапханә мөдире булган, 15 ел авыл советы рәисе вазифасын башкарган. Үз эшенә җаваплы караву, җаны-тәне белән бирелеп эшләве нәтиҗәсендә ул зур уңышларга ирешә, авылдашларының хөрмәтен казана, җитәкчеләр тарафыннан хезмәте югары бәяләнә. Санап бетергесез мактау грамоталары Илдус абыйның тырышлыгы, хезмәт сөючәнлеге турында сөйли.

Бөек Ватан сугышы башланганда, Илдус абыйга нибары 11 яшь була. Шул чорның башка балалары кебек, аңа да төрле эшләр башкарырга туры килә. Каюм, Рашит, Гани абыйлары сугыштан исән-сау әйләнеп кайтсын өчен, бик тырышып эшли ул. Җиңү көнен якынайтуда Илдус абыйның да өлеше зур була.

Бүгенге көндә Илдус абый Җиһаншин, авылыбызның иң хөрмәткә лаек кешеләренең берсе булып, тормыш иптәше, балалары, оныклары белән матур гомер кичерә.

**Гарипов Адил Илдар улы**
**9 сыйныф**

## Зиннәтова Оркыя Гыйниятулла кызы



1939 нчы елның кояшлы 26 нчы апрель иртәсендә Биектау районы Чыршы авылында Нигъмәтуллиннар гаиләсендә бер нәни генә кызчык дөньяга аваз сала. Әтисе Гыйниятулла белән әнисе Васфикамал аңа Оркыя дип исем кушалар. Ул гаиләдә 4 малайга бердәнбер кыз бала була. Шулай акрын гына көн артыннан көн үткән, күңелле җәйләр җиткән. Әти-әниләр тырышып эшләп, ә балалар яшел чирәмдә тәгәрәп үскән көннәрдә 1941 нче елның 22 нче июнь иртәсе бөтен илгә кайгы китерә. Дәһшәтле Бөек Ватан сугышы башлана. Дәү әниемнең  әтисе дә сугышка китә. Бу вакытта дәү әниемә бары  2 яшь була. Сугыш вакытында бөтен авырлык дәү әниемнең әнисенә һәм олы улы Мәхмүт җилкәсенә (аңа бу вакытта 9 яшь) төшә. Алар бөтен тормыш йөген тартып барганнар. Дәү әниемнең әтисе сугыш бетеп, 9 ел үткәч кенә туган якларына исән-сау әйләнеп кайта алган.

Дәү әнием бары 6 класс белем алган. Башлангыч белемне Чыршы авылында ала, аннан соң Дөбъяз мәктәбендә  укый. 6 класс  белем  алганнан соң, башка уку мөмкинлеге булмаган.  13 яшьлек кыз олылар белән беррәттән фермада эшли башлый.

1961 нче елда дәү әнием Чәмәк авылы егете Зиннәтов Камилгә кияүгә чыга. Алар 2 кыз һәм 2 малай тәрбияләп үстерәләр. Гомере буе дәү әнием гел эштә, гел хезмәттә булган. Ул колхозда бозаулар караган, үгезләр симерткән. Төрле бригада эшләрендә дә актив катнашкан.

Эшләгән дәвердә дәү әнием гел алдынгы урыннарда булган. 1989 нчы елда “Лучшему семейному подряду” дигән күчмә вымпел белән бүләкләнгән. 1991 нче елда “1 нче класслы терлекче” дип исемләнгән аттестат белән дә бүләкләнә. Ә истәлеккә бирелгән сәгать дәү әниемнең өендә әле дә булса келт-келт гомер минутларын саный.

Дәү әнием хәзер дә исән-сау, безнең белән гомер кичерә. Балаларына, оныкларына изге теләкләрен теләп, догаларын укып тора. Ә мин яхшы укуым, тәртипле булуым белән  дәү әниемне һәрвакыт куандырырга тырышам. Аның белән горурланып һәм  үрнәк алып үсәм.

**Әхмәтханов Әнис, 5 нче сыйныф**

# Исмагилова Нурзия Исмагыйль кызы



Исмагилова Нурзия Исмагыйль кызы 1937 елның 1 гыйнварендә, Дөбъяз районы Суксу авылында туган. 1940 нчы елгы энесе дә, сугыш башланганда 6 айлык бала булган. Семьяда 1941 елда әтиләре киткәндә 5 кеше кала. Әтисенең әтисе Галимов Газиз 72 яшьтә, әнисе Галимова Бибинур 70 яшьтә, әнисе 1920 елгы була, ул 1947 елда тормышка чыга, балалар бабайлар белән калдык.

кала. 1945 елда Суксу мәктәбенә укырга керә. 1953 елның маенда 7 классны бетерә. 1953 елның 1 августыннан Суксу авылында медпунктта санитарка булып, 1954 елның 1 июненнән 1973 елның августына кадәр Суксу авыл советында секретарь булып эшли башлый,. 1973 елның 1 сентябреннән 1978 елга кадәр заправщик булып эшли. 1978 дән 1980 елларда колхозда бригадир, 1980 елдан хезмәт хаклары буенча бухгалтер. 1986 дан 1996 елга кадәр мәктәптә техник хезмәткәр. Шуннан 44 ел стаж белән пенсиягә чыга.

Бабасы, әбисе колхозчылар була. Әтиләре сугышта һәлак була. Мәскәүгә җитәбез дип 1 хаты килде әтиегезнең дип йөрде әби. “Без бик авырлык белән,әтисез дә, әнисез дә үстек, башка бер кешебез, туганыбыз да булмады”-дип сөйләде безгә яшь аралаш Нурзия апа.

Нурзия апа 1956 елда тормышка чыга, тормыш иптәше белән 3 кыз тәрбияләп үстерәләр. Хәзерге көндә аның 7 оныгы, 5 оныкчыгы бар. Тормыш иптәше 2001 елда үлә, шуннан бирле үзе генә яши. Балалары атна саен кайтып хәлен белеп торалар. Булганына сөенеп, илгә-җиргә тынычлык теләп яши.



Нурзия апаның бүләкләре:

Татарстан Республикасының “Агент совместитель инспекции Гострахa”- дигән Мактау грамотасы белән бүләкләнгән.

1955 – 1957, 1959 – 1962, 1963 – 1965, 1967 – 1969, 1969 - 1971

Авыл советы депутаты. 1956 елларда Комсомол оешмасы секретаре

Хезмәт ветераны.

Данлыклы донор

**Закиров Зөфәр**
**9 нчы сыйныф укучысы.**

**Хәйруллин Мәннәф Хәйрулла улы**



Минем карт дәү әтиемнең исеме Хәйруллин Мәннәф Хәйруллович. Ул 1927 елның 5 мартында Дөбъяз районы Кондырлы авылында туган. Туган авылында 1 класс бетергән. Кечкенәдән колхозда эшли башлаган. Төрле эшләрдә эшләгән. 1965 нче елдан 1980 нче елга кадәр склад мөдире булып, ә 1980 нче елдан 1997 нче елга кадәр авылда бригадир булып эшләгән.

Сугыш башланганда дәү әтигә 14 яшь булган. 1942 нче елда сугышка аның Саттар исемле абыйсы китә һәм хәбәрсез югала. Сугыш вакытында дәү әтигә олылар башкара торган эшләрне эшләргә туры килә: үгез җигеп сука сукалаган, урман да кискән. Ашарларына булмаган. Бөтен ашлыкны фронтка җибәргәннәр. Ачлыктан кешеләр бик нык интеккәннәр. Безнең дәү әтинең әнисе складта эшләгәч, азмы-күпме ипи юнәлтә алган. "Кич белән сукыр лампа утын да кабызып утырырга ярамый иде. Немецлар килеп бомбага тотырлар дип курка идек",- дип сөйли дәү әти.



Дәү әти Бөек Җиңүнең 55 еллыгы хөрмәтенә Татарстан Республикасының истәлек билгесе белән бүләкләнгән. Сугыш вакытында күрсәткән хезмәтләре өчен медале белән, сугыш беткәннең 65 еллык юбилей медале белән бүләкләнгән.

"Бүтән андый сугышларны күрергә язмасын"- ди дәү әтием.

**Гатауллин Рамазан, 4 нче сыйныф.**

## Кадырова Роза Абдул кызы

Кадырова Роза Абдулловна 1943 нче елның 14 нче гыйнварында Биектау районы, Чәмәк авылында туган. Сугыш башланганда нибары 2 яшь кенә булган. Әтисе сугышка китә. Әнисе 2 бала белән кала. Көне-төне эштә була. Ике яшьлек сабыйны әнисе басуга күтәреп бара. Ул шунда көне буе күләгә астында ята. Әтисе Габдулла сугышта яралана. Бармагы төзәлмичә сугыштан азат ителә.

Роза апа 8 класс бетергән. Суыксу авылында Сигнал артелендә эшли. Аннан хуҗалыктан сөт җыя. Барлык эш стажы-40 ел. Ире Газинур абый белән 5 бала тәрбияләп үстергәннәр.

**Бикмуллина Энҗе, 5 нче сыйныф**

## Сафина Кәүсәрия Хидиятовна

Сафина Кәүсәрия Хидиятовна 1939 нчы елның 30 августында Кондырлы авылында туа. Сугыш вакытында Кондырлы авылында торган. Сугыш башланганда 2 яшь була. Сугышта әтисе Хидиятулла, әтисенең энесе Гарифулла катнаша. Әтисе яраланып кайта, ә энесе хәбәрсез югала. 7 класс белем ала. 4 класс Кондырлыда укыган, 3 ел Иске Рәстә. 3 бала үстергәннәр, берсе 25 яшендә үлгән. Соңгы вакытта фуражир, хуҗалыкта сөт җыйган. Социалистик ярышта җиңүче значогы белән бүләкләнгән. Өметсезлеккә бирелмәгән. Күкәри, ат кузгалагы, черек бәрәңге белән тукланганнар. Сугыш беткәч шатлыклы мизгелләр булган. Әтисе башта Сослангир лагерында булган, аннан сугышка алынган. Сугыштан исән-имин төнлә кайткан, өйгә туганнары җыелган. Сугыштан соң тормыш бик җиңел булмаган.

Яшь буынга теләкләре: сугыш әфәтләрен кхрергә язмасын, тырышып укысыннар, сау-сәламәт, бәхетле булсыннар.

## Касимова Мәшүрә Нуретдин кызы





Касимова Мәшүрә Нуретдин кызы, 1939 нчы елның, 20 нче июнендә Дөбьяз районы, Кече Рәс авылында туган. Шул авылда 7 класс белем туплаган. Сугыш башланганда 2 яшь булган. Нәни сабыйларның ашарларына да такы- токы. Кычыткан, кукәри (черек бәрәңге) – бөтен ризыклары шул. Кигән күлмәк-ыштаннары киндердән.


Хәлил абыйның сугышка әтисе, абыйлары: Нургали, Шиап киткәннәр. Сугыштан бары Шиап абыйсы гына исән - сау әйләнеп кайта.

Мәшүрә апа гомер буе колхоз эшендә эшли. Салам чыгара, чебиләр карый, яшелчәдә эшли..

Колхозда эшләгәндә "Ударник Коммунистического труда"-дигән мактау кәгазьләре белән бүләкләнгән.

## Касимов Хәлил Касыйм улы





Касыймов Хәлил Касыйм улы Дөбьяз районы, Кара Күл авылында туган. Башлангыч белемне Кара Күл авылында , ә калган 7 нче класска кадәр Киек авылында укый. Сугыш башланганда 6 яшь була. Шулай кечкенә булуына карамастан, колхозга эшкә чыга. Үгезләр сукалаганда аларны куып йөри, башак уруда катнаша. Рәхәтләнеп авыз тутырып ашарларына булмый. Бар ризыклары черек бәрәңге, кычыткан, алабута ашы. Кигән күлмәк-ыштаннары киндердән.

Әтисе сугышка китә. Әмма Сослангердан китә алмыйча, ачтан үлә.

Хәлил абый күп еллар дәвамында механизатор булып эшли, атлар карый. Бик күп мактау кәгазьләре белән бүләкләнә. Тормыш иптәше белән 4 бала тәрбияләп үстерәләр.

**Шәйхетдинова Зөһрә, 5 нче сыйныф**

**Низамиева Розания  Габдулхай кызы**

Минем дәү әни Низамиева Розания Габдулхай кызы, 1940 елның 21 августында Суксу авлында дөньяга килә. Сугыш башланган вакытта аңа нибары бер яшь кенә була. Бу сугышка аның әтисе, әтисенең ике абыйсы һәм әтисенең ике энесе китә. Әтисе хәбәрсез югала һәм дәү әни аны күрү бәхетенә ирешә алмый. Ул Суксу 7 еллык мәктәбендә 7 сыйныф белем ала, аннан соң ике ел кичке мәктәптә укый. Укып бетергәннән соң фермада, колхоз правлениясендә Һәм мәктәптә эшли. Эшләү елларында район мактау кагәзьләре белән бүләкләнә.

**Шакирҗанов Ильяс,  11 сыйныф**

**Шакирҗанов Әмир Шакирҗан улы**

Минем дәү әти Шакирҗанов Әмир Шакирҗан улы 1938 елның 13 нояберендә Битаман авылында дөньяга килә. Сугыш башланган вакытта аңа 2,5 яшьләр чамасы була. Сугышка әтисе, әтисенең абыйлары китә. Әтисе сугшыш кырында ятып кала. Битаман җидееллык мәктәбендә 7 сыйныф белем ала. Укып бетергәннән сон плотник хезмәтен башкара, аннан сон шахтада эшли. Шахтада эшләү чорында мактау кагәзьләре белән бүләкләнә.

**Шакирҗанов Ильяс,  11 сыйныф**

## Мусин Фоат Галимҗан улы

Мусин Фоат Галимҗан улы, 1942 нче елның 20 нче маенда Биектау районы, Ташсу авылында туа. (Элек Дөбьяз районы, Ташсу авылы). 7 класс белем ала. Гомер буе колхозда ат җигә. Дәү әтиемнең әтисе сугышка китә. 1942 нче елда хәбәрсез югала. Туганнары да сугышта һәлак була. Сугыш вакытында күргәннәрен әнисе сөйләгәннәрдән бик аз гына хәтерли. Әнисе көннәр буе басуда урак уруда була. Нәни балаларны өйдә калдыра. Ял иткән арада өйгә кайтып, аларны ашатып килә. Ашарына нәрсә - суга пешкән бәрәңге , ул булса, шулай ук кычыткан ашы. Иң авыр чорлар ул вакытта. Эш балалар, өлкәннәр өстендә. Кияргә кием дә юньле түгел,әллә ничә җирдән ямаулы. Әмма халык түзә. Җиңү якынайтуга күпме көчен түгә.

**Сабирова  Гөлия, 5 нче сыйныф**

## Нургалиева Мөнҗия Гыйлаҗ кызы

Дәү әнием - Нургалиева Мөнҗия Гыйлаҗ кызы 1938 елның 20 апрелендә Маҗар авылында туган. Сугыш башланган вакытта Маҗарда яшәгән, аңа ул вакытта 3 яшь булган. Сугышта аның әтисе һәм аның абыйсы Кыям, Хабибулла катнашкан. Алар икесе дә сугыштан исән-имин әйләнеп кайталар. Ул Маҗарда 3,4 класс укыган, Чуваш илендә 5-6 класс белем алган. Соңгы вакытта сыер савучы, бозау караучы булып эшләгән. Ул бозау караган өчен бик күп мактау грамоталары белән бүләкләнгән. Сугыш вакытында ашарга да булмаган. Сугыш башлангач ул әтисез дә калган. 1941 елны бик авыр кичергәннәр. Ул вакытта кузгалаклар, чикләвекләр, үләннәр ашаганнар. Сугыш вакытында алар кешеләргә бәрәңге казышып, өйләрен юышып тамак туйдырганнар. Мәктәптә укыган вакытта фермада бозаулар карарга булышканнар. Кечкенәдән үк өйгә су ташып, утын ташып үскәннәр. Җиңү турында әтисенең энесе Кыям кайткач белгәннәр. Кыямны бик шатланып, куанып каршы алганнар. Сугыштан соң да яшәү җиңел булмаган.

Бүгенге көндә 2 баласы исән: Лилия белән Ришат. Минем әтием һәм апам. Дәү әнием безнең белән яши. Безне тәрбияләүдә аның өлеше бик зур. Аның акыллы киңәшләрен мин һәрвакыт исемдә тотам. Аңа саулык-сәламәтлек телим. Ул үзе дә: “Шатлыклы мизгел сау-сәламәт булуың ди. Яшь буынга теләкләр шул: сау сәламәт булырга, әйбәтләп укырга”.

.

**Нургалиева Рузилә**
**8 нче сыйныф укучысы**

## Самитова Флёра Гатаулла кызы



Самитова Флёра Гатаулла кызы 1941 нче елның 16 нчы февралендә Биектау районы Ташсу авылында дөньяга килә. Әти-әнисе ул вакытта каһәр төшкән сугыш башланыр дип башларына да китермәгәннәрдер. 1941 нче елны сугыш башлангач ук әтисе сугышка алына. Әтисенең энесе дә сугышка китә. Иң авыр еллар шушы вакыттан башлана. Барлык ир-атлар сугышка китә. Тылдагы хезмәт картлар, балалар кулында кала.

Флёра апаның әнисе дә калганнар белән шул авыр йөкне тарта. Ашарга черек бәрәңге була. Шул гына ачлыктан коткарып кала аларны. Әтисе сугыштан исән - сау әйләнеп кайта, әтисенең энесе һәлак була.

Башлангыч мәктәпне Ташсу авылы мәктәбендә ала. 1955 нче елда Суксу мәктәбен тәмамлый. Шул вакыттан бирле Флёра апаның хезмәт юлы башлана. Аның эш урыны бер генә җирдә-фермада. Ул гомер буе фермада бозаулар карый. 42 ел эшләп лаеклы ялга чыга.Бик күп мактау грамоталары белән бүләкләнә, аның исеме мактау китабына кертелгән, хезмәт ветераны таныклыгына ия.

**Бикмуллина Энҗе, Хайруллина Гөлия**
**5 нче сыйныф укучылары**

## Сәйфуллина Әлфия Газиз кызы



Минем дәү әнием - Сәйфуллина Әлфия 1931 нче елның 20 июлендә Дөбьяз районының гүзәл табигатьле Таршна авылында Батырхановлар гаиләсендә 2 нче бала булып дөньяга килә. Ул вакытта такта түбәле өй. Урманнан утын ташып җылытыла. Юеш утын янып китми үзәккә үтә. Әбием бик чая, эшчән кыз булып үсә. 1939 нчы елда авылдагы башлангыч мәктәпкә укырга керә. 3 нче сыйныфта укыганда дәһшәтле Бөек Ватан сугышы башлана. Авылдагы ир-атлар барысы да сугышка алына. Дәү әниемнең дә әтисе сугышка китә. Барлык эш әнисенә, калган 4 баласына төшә. Сугыш башланганда аңа нибары 10 яшь тулган була. Башлангыч мәктәпне яхшы билгеләренә тәмамлап, Дөбьяз мәктәбендә укуын дәвам итә. Ачлы -туклы 4 километр җәяү йөреп укырга туры килә аңа. Кызганыч, бары 3 кенә ел укый ала. Башка йөреп укырга мөмкинлек чыкмый. Сугыш башлангач балаларны да эшкә тараталар. Әбием мәктәптән кайтуга колхозга эшкә китә. Ындыр табагында көлтәләр биреп тора, атлар куалый. Ул вакытта ашлык суга торган машиналарны атлар тартып йөри. Нәкъ шул вакытта атларны куалап торырга кирәк була. 10 яшьлек кыз бала бөтен буш вакытын колхоз эшендә уздыра. Эшләгән өчен аларга 200 грамм ипи бирәләр.Ул ипигә куана-куана эшкә җигеләләр. Мәктәпкә алып барыр өчен ризык була бит ул. Бер кисәк ипи өчен күпме көч түгәргә туры килә балаларга. Моның белән генә чикләнеп булмый. Кыш көне кар астыннан күкәри (черек бәрәңге) казып җыялар. Аны киптереп он ясыйлар. Шул оннан ипи пешерәләр. Буш суга пешкән бәрәңге, күкәридән, алабута үләненнән пешкән ипи - аларның бөтен ашаган ризыклары. Нишлисең, бөтен ил ил өстенә төшкән афәткә ничек тә түзәргә кирәк була. Дәү әнием дә кечкенә кыз бала булуына карамастан, Бөек Җиңүне якынайтуга үз өлешен кертә. Ләкин әтисе генә сугыш кырларында ятып кала. Ата назын да бик аз татып кала. Сугыштан соңгы чорлар да җиңел бирелми. Колхозда иң авыр эшләрдә эшләргә туры килә, сайланып утырып булмый эшләргә кирәк. Яшь кызларны чиратлап Әлбәттә инде дәү әнием алгы сафта була. Аннан 17 яше тулгач урман кисәргә Мантовкага 6 айга җибәрәләр. Монда да сынатмый ул . Ничек чыдаганнардыр алар шушы авыр эштә, күз алдына китерүе дә кыен. Урманнан кайткач төрле эшләрдә эшләвен дәвам итә. Печәнен дә чаба, симәнәсен дә ташый. 1963 нче елда Суксу авылы егете Равилгә кияүгә чыга. Монда да сынатмый, колхозда эшли. Нәни бозаулар карый, төрле авыр эшләрдә эшләп лаеклы ялга чыга.Эшләү дәверендә алдынгы хезмәте өчен бик күп мактау кәгазьләре ала. “Ана даны”, “Ветеран труда” медальләре белән бүләкләнә. Дәү әтием белән 7 бала тәрбияләп үстерәләр. Аларның һәрберсенең дә үз тормышы. Хәзерге вакытта дәү әниемнең 13 оныгы, 6 оныкчыгы бар.Кызганыч, дәү әтиемне мин белмим. Ул 55 яшьтә авырып, якты дөньядан иртә киткән. Дәү әнием 56 яшендә пар канатсыз калган.Хәзерге көндә ул безнең белән гомер кичерә. Дәү әниемне мин бик яратам. Аның йөрәк түреннән чыккан киңәшләрен һәрвакыт истә тотарга тырышам. Безнең арада әле бик озак, сау-сәламәт килеш яшәвен телим.



**3 нче сыйныф укучысы**

**Сәйфуллин Булат Илнурович.**

## Сафина Солтания Хәйретдин кызы

Дәһшәтле сугыш хәтирәсен инде ничә еллар үтсә дә Солтания апа ачык хәтерли. Үзенең истәлекләре белән безнең белән дә бүлеште.

Солтания апа 1928 нче елның 17 нче июнендә Биектау районының Рәс авылында туа. 5 класс белем ала.

1941 нче елның 22 июнендә Бөек Ватан сугышы башлана. Мәктәп ябыла . Әтисен сугышка озаталар. Сугышка шулай ук әтисенең энесе Гәрәфетдинне дә алалар. Әнисе 2 бала белән ялгыз кала. Солтания апа – 12 яшьлек кыз, әнисенә булышырга дип көне-төне эштә була. Нәрсә көткәнен дә дә белмиләр ул вакытта., эшлиләр дә эшлиләр. Нәрсә булса шуны ашыйлар. (кукәри, үләннәр).

Бик авыр була ул вакытта, бар нәрсәгә дә кытлык. Шулай да алар төшенкелеккә бирелмиләр. 12-13 яшьлек кызлар зурлар белән берлектә тылдагы авыр йөкне тарталар. Коркачыктан икмәк күтәреп ташыйлар. Әниләре сугышка оекбашлар бәйләп җибәрергә дә вакыт таба. Төннәрен йокламыйча бәйли ул аларны. Бәлки берәрсе иремә эләгер дип өметләнә.

Шулай бервакытны Коркачыктан ипи күтәреп кайтканда , бер таныш булмаган абзый сугыш беткәнен хәбәр итә. Ул вакыттагы куанганлыкны сөйләп бетерә торган булмый. Авыл халкы өметләнеп сугыштан кайтучыларны көтә башлый. Солтания апаның әтисе сугышта яралана, шулай да исән-сау әйләнеп кайта. Гәрәфетдин абый һәлак була.

Сугыштан соңгы еллар да җиңел бирелми. Әмма әтисенең исән- сау әйләнеп кайтуы аларга алга таба да көч табып яшәргә, эшләргә ярдәм итә.

42 ел “Ульянов” колхозында төрле эшләрдә эшләп лаеклы ялга чыга. Бүгенге көндә балалары - Кодесия, Мәхмүт,Мөнир, Тәслимә, Әмир үз тормышлары белән яши. Горурланып әйтерлек балалар үстерә Солтания апа. Ул II дәрәҗәдәге “Ана даны” медале белән бүләкләнгән. Хезмәт ветераны, Сугыш ветераны таныклыгына ия.

“ Җир йөзендә берәү дә сугыш әчесе күрмәсен, без күргәнне бүтән берәүгә дә күрергә язмасын. Исәнлек-саулык белән, ходай биргәнгә шөкер – ана кылып, бу тормышның һәрбер көненә сөенеп яшәсеннәр”- дип теләкләр тели-тели безне озатып калды.

**Сабиров Илнар**
**8 нче сыйныф укучысы.**

## Сәмигуллина Суфия Галимҗановна

Сәмигуллина Суфия Галимҗан кызы 1926 нчы елның 12 нче декабрендә Дөбьяз районы Рәс авылында туа. 3 класс белем ала. Мәктәпкә киеп йөрергә аяк киеме булмый Суфия апаның, булганын урлыйлар. Шуннан әнисе чирләп китә. Авыру әнисен карап, укый алмыйча кала. Сугыш башланганда аңа 15 яшь тулган була. Сугыш башланганын Суфия апа икенче бер колхозга икмәккә баргач белә.Ул инде өлкәннәр белән берлектә колхозның барлык эшендә актив катнаша. Иң кайнар эш вакыты-урак урган вакыт була. Уракны кул белән уралар, кул белән сугалар. Көне-төне басуда эшлиләр алар.

Сугышка аның ике туганы китә, кире әйләнеп кайтырга насыйп булмый. Сугыш башлангач хәлләр тагын да авырлаша. Бөтен ир-атлар да сугышка китә. Барлык хезмәтне карт-карчыкларга, яшь балаларга башкарырга туры килә. Хәлләреннән килгәнчә эшлиләр алар. Ашарларына да юньләп булмый. Черек бәрәңгене дә Чуваш Иленнән алып кайтып ашыйлар. Алабута, кычыткан ашы белән туклаланалар. Шулай булса да көчле рухлы булулары, авырлыкларны җиңәргә ярдәм итә. “Сугыш вакытында эшләп хәлдән тайган карчыкларны күтәреп кайта идек”- дип сөйли яшь аралаш Суфия апа.

Җиңү шатлыгын басудан кайтканда беләләр. Рус кызлары килеп биергә куштылар. Без аптырап калгач “Войне конец!”-дип кычкырдылар. И ул вакытта шатланганыбыз. Әле дә күз алдында торган кебек.

Сугыштан соң гына хәлләр җиңеләйми. Бик азапланып яшәдек. Шырпы булмады, керосинга кытлык булды. Кемнең өйләреннән төтен чыга, шулардан ут алып кайтып, мичкә яга идек .

Булачак тормыш иптәше сугыш бетеп, 3 ел үткәннән соң әйләнеп кайта. Аннан өйләнешәләр. Бергәләп 4 бала тәрбияләп үстерәләр.

Суфия апа бер эштән дә чирканмый. Сарыклар да карый, сыерлар да сава. Пенсиягә чыкканчы армый-талмый эшли. Тормыш иптәше генә иртә үлә.Озак еллар тол булып яшәргә туры килә. Шулай булса да сабыр холыклы апа төшенкелеккә бирелми. Хәзерге вакытта улы Искәндәр тәрбиясендә бәхетле гомер итә.

Яшь буынга теләкләре: “Кабаттан сугышлар булмасын, әти-әниләрнең сүзләрен тыңлап, сау-сәламәт яшәүләрен телим.

**Айзетуллова Диана**
**8 нче сыйныф**

# Усманова Мәсхүдә Исмәгыйль кызы



Матур хыяллар белән янган, яшьлек елларынд шәхси тормышларында күп кыенлыклар кичергән сугыш елы балаларының татар тарихында эзләр йөрәктә әйткән сүзләре мәңге саклансын. Аларны язмышлары күпләр өчен үрнәк алырлык, сокланырлык. Алар зур ихтирамга лаеклы кешеләр. Шундыйларның берсе Кече Рә авылында гомер кичерүче Мәсхүдә апа.

Усманова Мәсхүдә Исмәгыйль кызы 1930 нчы елның 21нче ноябрендә Кече Рәс авылында дөньяга килә. Исмәгыйль абый белән Сабира апаның көтеп алган беренче балалары була.

С ... чке бер ... ій. сугышка китеп беткәч, бөтен а... Алар ачы хәсрәтне йөрәкләренә иотып, сугышның барлык җәфаларын иңнәренә салып, ут эчендәге якын кешеләре өчен эшлиләр. Сугыш башланганда Мәсхүдә апага 11 яшь була. Мәсхүдә апа да нинди генә эшләр башкармый. Урак уру дисеңме, ерак җирләрдән күтәреп чәчүлек орлыгы ташу дисеңме, печән чабу – барысы да аның кулыннан да уза. Мәсхүдә апага 13 яшь булганда, әти – әнисе вафат булалар. Ятимлек ачысын бик авыр кичерә ул. 10 яшьлек энесе белән икесе генә калалар. Ашарга ризык, киенергә кием булмаса да, ул энесен барлык авырлыкларны җиңеп, карап үстерә. Әйтерсең лә, Мәсхүдә апаны кайгы сагалап кына йөргән. 19 яше тулгач, энесе Исхак абый да үлеп китә. Ходайдан сабырлык сорап, тормышын дәвам итә ул.

Авылның уңган, тырыш гүзәл кызын Усманов Гомәр абый тормыш иптәше итеп сайлый. Алар берсеннән – берсе акыллы, тырыш, игелекле 5 малай тәрбиялэп үстерәләр: Әнвәр, Әдһәм, Әнис, Әгъзәм, Наил.



Мәсхүдә апа авылда бик тырыш, эшчән, уңган хатын була. Колхозда нинди генә эшкә кушсалар да, куркып калмаган. Язмыш аңа олыгайгач та бер – бер атлы кайгыларны китереп кенә тора. Улы Әгъзәм бик яшьли үлә. Тормыш иптәше Гомәр абый да, Мәсхүдә апаны ялгызын гына калдырып үлеп китә. Сагыш, югалту бик күп була Мәсхүдә апа тормышында.

Хәзергесе вакытта Мәсхүдә апага 83 яшь. Ул бик бәхетле ана. Балалары атна саен кайтып хәлен белеп, булышып торалар. Киленнәрен дә, малайларын, оныкларын да мактап туя алмый ул. Бүгенге матур, тыныч, мул тормышка куанып яши.

**Сабиров Илнар Данил улы**
**8 нче сыйныф**
**укучысы**

# Фаттахова Нәгыймә Замир кызы



Егерме ике. Июнь. Кырык бердә...

Җиргә афәт килде ул көнне.

Тарих каһәрләгән шушы көнне

Мөмкинме соң оныту, мөмкинме?

Сугыш беткәнгә күпме еллар узса да, аның дәһшәтле хатирәләре кешеләр күңелендә әле дә саклана. Бигрәк тә шул чорның авырлыгын үз җилкәләрендә үткәргән кешеләр саклый бу хәтерне. Нәгыймә апа да бу дәһшәтле сугыш турында күз яшьләрен сөртә-сөртә сөйләде.

Фаттахова Нәгыймә Замир кызы 1930 нчы елның 2 апрелендә Дөбьяз районы Кече Рәс авылында гади колхозчы гаиләсендә дөньяга килә. Кече Рәс мәктәбендә башлангыч белем ала. Сугыш башланганда Нәгыймә апага 11 яшь була. Ул елый – елый, теләкләрен теләп әтисен, Замир абыйны сугышка озата. Гаиләдә 5 бала кала. Нәгыймә апаның әнисе бу балаларны ничек аякка бастырырмын икән? Ничек көн күрербез дип, төн йокламый борчыла. Бер эштән дә куркып, каушап калмый. Ирләр эше дисеңме, хатын кыз эшеме, барысында җиренә җиткереп тормыш арбасын тарта. Әнисе кебек, Нәгыймә апа да бер эштән дә куркып калмый. Фермада сыер да сава, таналар да карый. Кул белән ферма терлекләренә печәнен дә чаба, урманын да кисә. Авылның башка эшләрендә дә булышмый калмый. Нәгыймә апаның әтисе сугыштан гарипләнеп кайта. Бүгенгесе көндә Нәгыймә апаның әти – әнисе гүр ияләре.



Нәгыймә Замир кызының хезмәтләрен дәүләт югарый бәяли. Бөек Ватан сугышындагы “Фидакарь хезмәте өчен медале”, Җиңүнең 50, 55, 60, 65 еллыгына бирелгән юбилей медальләре, Республика Указы нигезендә бирелгән “Хезмәт ветераны” медале белән бүләкләнә.

Тормыш иптәше Фаттахов Әсхат абый белән 50 ел бергә гомер кичеләр. 3 егет тәрбияләп үстерәләр. Аларның һәркайсы үз томышлары белән яшиләр. Бүгенгесе көнгә Нәгыймә апа язмышына бик рәхмәтле. Без яшь буынга кайсы гына якны алсак та, бар яктан да алар үрнәк безгә.

**Усманов Рүзәл Рамил улы**
**8 нче сыйныф укучысы**

# Хәкимҗанова Шәмсеруй Шакир кызы



Минем дәү әнием Хәкимҗанова Шәмсеруй Шакир кызы (Бикмөхәммәтова) 1931 елның 5 нче апрелендә хәзерге Биектау районы Айбаш авылында (элек Арча районына кергән) Шакир һәм Мәйсәрә атлы кешеләр гаиләсендә туган. Әтисе сугышка кадәр бай кешеләргә барып хезмәт иткән, сугыштан соң колхозчы булган, оста мич чыгарган. Әнисе дә колхозда эшләгән, башкалар белән бунты (эскерт) өеп йөргән. Гаиләдә алар өч бала булган: энесе Сәлахетдин, апасы Зөлхәбирә исемле. Әтисе сугышта булган, көннәрнең берендә йөрәге сау булмау сәбәпле аны сугыштан кайтаралар. Аннан соң әнисе өч баланы калдырып окоп казырга Лаеш ягына киткән. Кайткач, ире урынына Гәргә урман кисәргә төшеп китә, бер айдан соң гына кайта. “Әтиебез бер, ана башка булган Гыйният абыем да сугышка китте, исән – сау әйләнеп кенә кайта алмады”, - ди дәү әнием.

Әти – әни назында гына яшәү туры килмәгән бу чор балаларына. Дәү әнием бу турыда болай дип искә ала: “2 класс кына укый алдым... Чәчү чәчтем, укырга мөмкинлек булмады, машина ашлык сукканда ат куып йөрдем, атлар карадым. Сугыш вакыты бик авыр булды шул, Казанга барып ипи алып булмый, чират торасың, ашарга юк, яшәр өчен кузгалак, бәрәңге яфрагы, черек бәрәңге ашадык...”

19 яшендә күрше Суыксу авылы егете Галимҗан (минем дәү әтием) белән тормыш корып җибәрәләр. Дәү әни колхозда фермада сыер сава. Уңган, булган дәү әнием авыл советында дүрт ел депутат булып тора. Хезмәте өчен бик күп Мактау грамоталары белән бүләкләнә. Алар хезмәт производствосында эшләп, югары күрсәткечләргә ирешкәне өчен, сыер савучылар арасында гел алдынгы урынны алганы һәм терлекчелектә намус белән эшләгәне өчен бирелә аңа.



Дәү әти белән дәү әни җиде бала тәрбияләп үстергәннәр. Быел дәү әни һәм дәү әтинең бергә гомер итүләренә 60 ел булыр иде, дәү әтием кинәт кенә авырып үлеп китте. Бүгенге көндә без дәү әни белән яшибез, аның барысы егерме ике онык һәм оныкчыгы бар. Әле дә һәммәбезне тәмле өчпочмаклары, сөзмәләре белән сыйлый дәү әнием. Без аны бик яратабыз. Саулыгы белән безнең янәшәдә яшәвен һәм озын гомер телибез.

***Суыксу мәктәбе укучылары Нияз һәм Азат Хәкимҗановлар.***

2014 ел.

## Хакимова Илхамия Хәким кызы



Минем әниемнең дәү әнисе 1924 нче елның 18 июнендә элеккеге Дөбьяз авылы Суксу авылында дөньяга килә. Әтисе Бикмөхәммәт улы Хәкимулла, әнисе Биктаһир кызы Бибигайшә исемле була. Гаиләдә алар 9 бала булалар. Хәзергесе көндә әбиемнең бертуганнары арасында берсе дә исән түгел. 1932 нче елда Суксу мәктәбенә беренче сыйныфка укырга керә. Шушы мәктәптә, шушы авылда дүрт сыйныфны тәмамлый. Урта сыйныфларда уку өчен Чәмәк авылына барып укырга кирәк була.Чәмәк авылында мәктәп - җидееллык. Чәмәк авылына барып ике генә атна укый ул. Әти-әнисенең саулыгы бик нык булмый.

Әнисенең бер аягы һәм кулы зәгыйф була. Гаиләдә балалар күп булгачтын, әбием әти-әнисенә ярдәм итү өчен бишенче сыйныфта ике атна укыгач , колхозга эшкә чыккан. Колхозга эшкә чыккач ул бик тырышып эшли, олылардан калышасы килми аның. Унбер-унике яшьлек балалар, зурлар белән бергә, урак урганнар, көлтә бәйләгәннәр, әвеннәрдә кул машинасы белән ашлык чистартырга йөргәннәр.

1941 нче елның 22 нче июнендә немец юлбасарлары безнең илебезгә сугыш башлый. Ул вакытта барлык ир-атлар сугышка киткән. Авылда хатын-кызлар, әби-бабайлар, яшь балалар гына калган. Әбиемне 1941 нче елның җәендә үк, авылдагы башка хатын-кызлар белән бергә, Яшел Үзән ягындагы урманнарны кисәргә җибәрәләр. Ике-өч көнгә генә эшкә барабыз дигән кызлар, салкын көз айларына кадәр шул урманнарда агач кисәләр. Баштарак ашарларынабулган, өйдән дә әйберләр алып килгән булганнар. Тора-бара ризыклар бетә башлаган, алар ачлы-туклы яши башлаганнар. Бик каты ашыйсы килүләреннән хәлләре китеп егылып та китә торган булганнар. Әбием әле дә бу авыр минутларны күз алдына китерә, исенә төшерә. Безнең ашарга тәмле-тәмле ризыклар булуына ул бик куана.

1941 нче елның кышына кергәндә, аларны Апас районындагы Колгына дигән авыл читенә окоп казырга җибәрәләр. Эшләгәндә шушы авылда торганнар алар. Авылдан җәен киткәнгә, аларның өсләренә җылы кием, ашарларына ризык бик аз була. Кыш салкын килгән. Алар кырык биш градус салкыннарда учак янында гына әзрәк җылынып ала алганнар. Аяклары бик туңганн, чөнки кияргә агач башмаклар гына булган. Алар барысына да түзгәннәр.

1942 нче елның язында аларга өйләренә кайтырга ризалык биргәннәр. Әбием бик куанган: “Аллага шөкер, әти-әниемә эшләренә булышырмын, ярдәм итәрмен” - дип өметләнеп кайткан кыз.1942 нче елның җәендә аларны авыл Советына кабат җыйганнар. Алты айга гына Кемерова ягына эшкә җибәргәннәр. Бу юлы Суксу авылыннан 4 кыз чыгып киткән: Гиниятова Суфия, Шәмсетдинова Мәрьям, Садриева Надия һәм минем әбием.Чәмәк авылыннан ике кыз: Маһинур һәм Хәлимә, Ташсудан: Фәүзия, Әминә, Рәстән - Рәйсә, Кондырлыдан Фатыйма исемле кызлар белән киткән ул. Юлда алар унбер тәүлек булганнар. Аларны хайван йөртә торган вагоннарга утыртып җибәргәннәр. Кулларыны бер кисәк дуңгыз салосы һәм 200 грамм тирәсе ипи биргәннәр. Поездлар барганда икешәр тәүлек туктап торып барган. Аларның ашарларына да беткән.

Кемеровага бик авырлыклар белән барып җиткән алар. Торыр өчен аларны этажлы итеп ясалган караватлары булган салкын тулай торакка урнаштырганнар. Кызлар вагоннар белән алып килгән зур-зур тимерләрне, капчык-капчык төялгән цементны бушатканнар. Цементтан чәчләре катып беткән, аны елый-елый тарый торганнарын әбием әле дә хәтерендә тота. Баганетка белән күмер түккәннәр, завод түбәләрендә кар көрәгәннәр. Салкын кышта, аяклары туңудан, агач башмакларда катып кала торган булган. Кышын-

җәен, кояш чыкканчы ун километр араны җәяү узып, урманга бара идек. Анда машиналарга агач ярганнан калган такта кырыйларын төяп торганнар. Көненә ничә машина килсә, шуны төяп бетермичә урманнан кайтмаганнар.

Алты айга киткән кызлар Кемерова ягында ике ел эшләгәннәр. Аннан соң аларны башка поселокка күчергәннәр (поселокның исеме Барсис). Монда шулай ук урман кисү эшендә эшләгәннәр. Агачны алар кул белән кискәннәр. Агачлар берсе өстенә икенчесе авып, алырга авырлаша торган була. Шул вакытта ирләр килеп, бер агачны икенчесе белән бәрдереп төшерә торган булганнар. Ул агачларны хатын-кызлар бутаганнар, кирәкле озынлыкка куеп кискәләгәннәр. Киселгән агачны, балакушкага бәйләп төяп, урман читенә чыгырганнар. Җыелган агачны тракторга төягәннәр. Төялгән утынны тимер юл тирәсенә китереп бушатканнар. Төнне аның янына вагон китереп куя торган булганнар. Шуны төяргә тагын хатын-кызлар барган.

Сугышта күргәннәре турында әбием күп сөйли, күзләреннән гел яшьләрен сөртә. Сугыш бетү турындагы хәбәрне алар бик зарыгып көтәләр. Ул көн килә. Ләкин аларны сугыш җимерекләрен торгызырга дип, тагын бер елга тоткарлыйлар.

Сугышка минем әбиемнең Сөнгатулла исемле абыйсы да китә. Сугыш башланган вакытта ул армия сафларында була. Соңгы хатында, кайтырына илле ике көн калуы турында язган ул. Ләкин сугыш үзенекен иткән. Сөнгатулла абыйсын армиядән туры сугыш кырына җибәргәннәр. Шулай итеп, ул гомеренең җиде елын читтә үткәрә.

1946 нчы елның җәй аенда, әбием Сөнгатулла абыйсы белән Казанда очрашып, бергә эти-әниләре янына кайталар. 1950 нче елда авылның Габдулла исемле (минем бабам) кеше белән тормыш коралар. Гаиләдә дүрт бала тәрбияләп үстерәләр алар. Хәзергесе көндә бабам вафат инде, ә әбием килене Тәнзилә (минем дәү әнием) белән яшәп ята. Олы улы Дамир (минем дәү әтием) авырып үлеп китте. Алар бергә утыз биш ел тату гомер кичерделәр. Әбиемә бала ачысы да татырга туры килде . Бүгенгесе көндә әбиемнең тугыз оныгы, дүрт оныкчыгы бар. Ул үзенең балаларын гына түгел, калган унөч онык-оныкчыгын тәрбияләүдә дә зур өлеш кертә. Тормышта ул сабырлыгы, тырышлыгы, акыллылыгы, төпле киңәш бирүчәнлеге белән калганнардан күпкә аерылып тора. Ходай аны изге кеше итеп яраткан, шуңа күрә саулыгын, зиһенен теләп биргән.

Сугыш елларында тырыш хезмәт күрсәткәне өчен дәүләтебез дә әбиемәне онытмаган: төрле медальләр белән күкрәген бизәгән. Һәр ел саен Җиңү бәйрәмендә Суыксу Җирле үзидарә советы, Суыксу гомуми урта белем бирү мәктәбе һәм мәдәният хезмәткәрләре тарафыннан зур бәйрәм оештырыла. Шушы бәйрәмгә баруны ул зур тантана итеп кабул итә. Яшь буынның, олыларга - аларга тыныч тормыш бүләк итүдә катнашучыларга - зур ихтирам белән карауларына шатлана ул. Мондый эчтәлекле чаралар уздыра ала торган үсеп килүче мәгънәле яшь буын булганда, киләчәккә өмете зур әле аның.

**Шигабиева Зөһрә**
**8 нче сыйныф укучысы**

## Хәбибуллина Хәвәрия Минһаҗ кызы

Хәбибуллина Хәвәрия Минһаҗ кызы 1938 нче елның 1 нче февралендә Чәмәк авылында туган. Әтисе Гайнетдинов Минһаҗ сугыш башлануга сугышка китә.Әнисе 4 бала белән кала. Сугыш ачысын бөтенләе белән татырга өлгерә дәү әнием. "Сугыш вакытында күргәннәрне әйтеп бетерерлек түгел"-дип сөйли ул . Әтисе яраланып сугыш беткәч кайта. Биле бөтенләй чәрдәкәнеп беткән була. "Шуышып барганда мина кыйпылчыгы чәчрәде"-дип сөйли иде ул. Үзе генә торып утыра алмады. Әнисе матчага сөлге асып куеп, шуңа гына ябышып тора иде.Бик озак еллардан соң гына аякка баса. Чәмәк авылында сарык фермасында кышын каравыл тора, җәен сарык көтүе көтә. Эшен намус белән башкара. Дәү әнием 7 класс укыган, аннан колхоз эшендә эшли башлый. Гомер буе төрле эшләрдә эшли.

**Хәбибуллина Земфира, 5 нче сыйныф**

## Хөснетдинов Габделхак Кадыйр улы



Хөснетдинов Габделхак Кадыйрович 1936 нчы елның 7 июлендә Чәмәк авылында колхозчы гаиләсендә туган. Чәмәк авылында 2 класс белем алган. 12 яшьтә колхозда ат белән төрле эшләрдә йөргән, шул яшьтән эшли башлаган.

Әнисенең абыйсы сугышта үлгән, 2 энесе, әтисе сугыштан яраланмыйча исән-имин кайткан. Габделхак абыйның балалары юк. Хатыны Фәхирә апа белән 50 ел гомер итә. 2007 нче елны хатыны вафат була.

Хезмәт стажы 46 ел, колхозда гомер буе хайванчылыкта эшләгән. Хәзерге вакытта пенсиядә.

Сугыш башланганда кечкенә булганмын, аңламадым. Әти сугышка киткәнен дә белмәдем. Ул сугыштан кайткач кына – аның әти икәнен белдем,-ди. Һәрвакыт кычытканлы аш, черек бәрәңге ашадык, шул гына ачлыктан коткарып калды. Сугыш турында бары начар хәтирәләр генә калды. Ачлык, ялангачлык, ягарга утын юк.



1939 нчы елгы сеңелем ачтан, шешенеп үлде. Калганнарыбыз 5 бертуган исән килеш сугыш вакытын кичердек. Әни нәрсә дә булса табып кайтып пешерә иде. Укыганда бернәрсәм дә булмады, ике кулымны селкеп менә идем мәктәпкә. Җиңү турында әти сугыштан кайткач белдем. Сугыштан кеше кайткач, җыелып кеше килә иде, хәлләрен белешәләр, сугыш хәлләрен сорашалар иде. Сугыштан соң да авыр яшәдек, ачлы-туклы, кияргә кием юк иде. Өйдә сыер бар иде. Шуның аркасында ашарга сөтебез булды.

Шулай да бүгенге киләчәгенә риза ул. Бик рәхәт заманда яшибез.Киләчәк буын шуның кадерен белеп яшәсеннәр. Яшьләр наркоман булмасыннар, аракы

**Низамиев Булат, Ришат.**
**4,7 нче сыйныф укучылары**

# Хузяшова Рузалия Гариповна



Хузяшова Рузалия Гариповна 1942 нче елның 22 нче маенда Чәмәк авылында дөньяга килгән. Чәмәк мәктәбендә 7 класс белем алган. Аннан төрле эшләрдә эшләгән. Бәрәңге басуы утарга, ашлама тутырыга йөргән. Әтисе сугышка китеп әйләнеп кайтмаган. Аның балачагы ятимлектә үткән. Үземне белә башлаганнан бирле бик начар яшәдек. Булышырга ир-атларыбыз да юк иде ди Рузалия апа. Әнисе дә гомере буе ялгыз яшәгән. Үзенә дә насыйп ярын табарга насыйп булмаган, балалары да юк. Хезмәт стажы 34 ел. 4 ел сарык караган. 30 ел сыер сауган. Хәзерге вакытта пенсиядә. Бертуган сеңлесе белән гомер кичерәләр.

# Гарипова Нажия Гариповна



Гарипова Нажия Гариповна 1929 нчы елның 12 июнендә Чәмәк авылында туган. Сугыш башланганда аңа 12 яшь була. 1-2 ел мәктәптә укыган эштән бушаган вакытларында. Сугышка әтисе, әтисенең 2 энесе, әнисенең 3 энесе киткән. Берсе дә сугыштан кайтмаган. Кияүдә түгел, балалары юк. Чәмәк авылында бозау карап, бедон юып, төрле вак эшләрдә эшләп пенсиягә чыккан.

Сугыш башланганын кешеләр сөйләгәч, ир-атларны җыя башлагач белдек ди ул. Ул елны бик салкын булган. Әтиләре сугышка киткәндә өйдә 6 бала кала. Өйдәге сыерны әтиләре асрый алмассыз дип саткан. 2 кәҗә алганнар шуның сөте белән тукланганнар, болында нинди ашый торган үлән бар, шуларны ашаганнар, бәрәңге чыккач, аның яфракларын ашый башлаганнар, шуннан бәрәңге булмаган. Нажия апа бик ябык булган, ул бәрәңге басуына барып, яз көне кукәри җыя торган булган. Башка кеше болчыракта бата икән, Нажия апа ябык булгач батмый, бик күп итеп күкәри җыя икән. Шулай итеп ул авылдашларына да өләшкән. Ачлык, ялангачлык булган. Казаннан кешеләр ишетеп кайта торган булган. Алар кием-салым алып кайтып күкәригә алыштыра торган булганнар. Шулай итеп без хәер сорашырга чыкмадык. Әтиләре сугышка киткәч аларны Сослангер лагерында ябып тотканнар. Кешеләр бик каты авырудан, ачлыктан корылган. Шуннан бер үткене Ворошиловка хат язган. Шуннан соң гына аларны бер бик каты сугыш булган җиргә керткәннәр. Әтиләре шунда үлгән. Солдатлар кайта башлагач, җыелышларда әйтә башлагач сугыш беткәнен белгәннәр. Бик куандык, еладык. Солдат кайткан өйгә кеше килә иде. Минекен күрмәдеңме? дип сорашырга бара иделәр.

Сугыштан соң да бик начар яшәдек. Бер нәрсә дә юк. Апа чабата ясарга өйрәнде. Шуны сата идек. Шул кәсеп кенә аларны ачлыктан коткарып калган. Шулай итеп алар авырлык белән гомер кичергәннәр. Насыйп ярын тапмаган Нажия апа. Сеңлесе белән икесе ялгыз калганнар. Шулай да төшенкелеккә бирелмичә, булганына шөкер-ана кылып гомер итеп яталар. Нажия апа “Ветеран ВОВ” таныклыгына ия. Бүтән бүләкләре юк.

**Низамиев Булат**
**7 сыйныф**

## Шакиров Ризван Габдрахман улы



Сугыш... Җимерелгән авыл, шәһәр, күпер, мәктәп, завод-фабрикалар... Иң куркынычы - вакытсыз өзелгән гомерләр, коелган кан... Кешеләр бу елларда кичергән авырлыкларны сөйләп кенә бетерерлек түгел, ә балачаклары урланганнар күргән җәфаларны күз алдына китерү дә куркыныч. Сугыш елы балалары... Бу язмам шуларның берсе - Ризван абый турында. Ризван абый 1930 нчы елның 5 нче октябрендә туа. 7 класс белем ала.

Сугыш... 1941 нче елда башланган каһәр төшкән сугыш. Ул вакытта аңа бары 11 яшь була.

Сугышка яраклы барлык кеше дә сугышка китә. Тормыш авырлыгы тулысы белән әниләр һәм әле ныгып та җитмәгән, балачакларыннан да айнымаган балалар җилкәсенә төшә. Бер кайгысыз уйнап йөргән, тук көннәр онытыла. Ул вакытта ачлык, өс-баш киемнәре җитми. Алар алабута күмәче, бәрәңге кәлҗемәсе ашап үсәләр.

Ризван абый колхозда төрле эшләрдә эшли. Ул чакларда күп эшләр кул очыннан үткәнгә, бик авыр була аларга. Гектары белән урак уралар, чүп утыйлар, кыскасы , кайда кушсалар шунда эшлиләр. Әтисе, әтисенең абыйсы сугышка китәләр.Әниләре балаларын кочаклап тол кала. Сугыш дәвам итә. Тормыш көннән-көн авырая. Фронттан өчпочмак кадәрле хатлар килә. Алар сагыну белән сугарылган. Тик сугышның беренче шомлы билгеләре – кара пичәтле хатлар да күренә башлый. Әтиләрнең-абыйларның сугышта батырларча һәлак булулары турында була ул хатлар. Мондый хат Ризван абый гаиләсенә дә килә. Аның әтисе дә, абыйсы дә һәлак була. Шулай итеп сугышның тиз генә бетүенә өметләр юкка чыга. Кайгырып утырып булмый, эшләргә кирәк. Сугышчыларга икмәк озатырга кирәк. Оекбаш-бияләйләр бәйләргә дә дә вакыт табу бик мөһим. Әйе, авыр булса да түзәләр. Ниһаять көтелгән көн килеп җитә. Радиодан Бөек Җиңү шатлыгын хәбәр итәләр. Әкренләп авылга исән калган сугышчылар кайта башлыйлар. Тик Ризван абыйның гына әтисе кайтмый.

Көн артыннан көннәр үтә. Ризван абый колхозда төрле эшләрдә эшләвен дәвам итә. Бригадир, тракторчы , деспетчер булып эшли. Аның гомуми хезмәт стажы 46 ел. Тормыш иптәше Фәүзия апа белән 3 малай, 2 кыз тәрбияләп үстергәннәр. Балалары барысы да үз юлларын тапкан. Үзләре янына чакырсалар да аларның авылларын ташлап китәселәре килми. Бүгенге көндә алар икесе тату гомер кичерәләр. Балалары бик еш яннарына кайтып хәлләрен белеп торалар.




## Шакирова Фәүзия Шакирҗан кызы

Балачагы сугыш чорына туры килгән баланың берсе Фәүзия апа. Ул 1930 нчы елның 11 декабрендә Суксу авылында туа. Сугыш башланганда аңа нибары 11 яшь була. Сугыш гарасаты тынганнан да байтак еллар үтсә дә, аның югалту ачылары бик ачы, яралары һаман ачык, күз яшьләре бик кайнар әле. Фәүзия апа сөйләгәннәрне дә күз яшьсез тыңлап булмый. 11 яшьлек кыз сугыш чорында колхозның барлык эшләрендә дә актив була. Көндезләрен укый, мәктәптән кайткач эшкә ашыга. Эшләгән өчен аларга 200 гр. ипи тия. Ашаган ризыклары моннан тыш кукәри, үлән ашы. Кигән киемнәре дә иске, тузган. Ул вакытта барлык эш кулдан эшләнә.Кеп-кечкенә куллар урак та ура, башак та җыя, башка төрле авыр эшләрдә катнаша. Гомер буе колхозда эшли Фәүзия апа. 7 класс белемне алганнан соң лана аның хезмәт юлы. 40 ел эшләп лаеклы ялга чыга. Ризван абый белән тигез картлыкта гомер кичерәләр.

**Хакимова Илүзә, 6 нчы сыйныф.**

**Шакирова Мөршидә  Гыйлаҗ кызы**



Шакирова Мөршидә апа 1928 нче елның июлендә Биектау районы Ташсу авылында туган.

Башлангыч белемне үз авылларында алган, аннары укуын Чәмәк мәктәбендә дәвам иткән. Тормыш авыр булу сәбәпле, аңа нибары 4 класс кына укырга насыйп була. Сугыш башланганда, Мөршидә апага нибары 13 яшь була. Кечкенә булуына карамастан, олылар белән беррәттән эшләргә туры килә аңа. Урак та ура ул, ат көтүе дә көтә, нәни бозаулар карый. Әти-әнисенең төп ярдәмчесе була.

Мөршидә апа сугышка киткән туганнарын хәтерләми, бөтен гаилә өстенә төшкән ачы сугыш хәсрәте алар гаиләсен читләтеп үтмәгәнен. Җиңү көнен якынайту өчен, бөтен көчләрен куеп эшләгәннәрен исеннән чыгармый.

Мөршидә апаның "Хезмәт ветераны" медале бар. Бу аның тырыш хезмәт нәтиҗәсе. **Шәйхетдинова Сәҗидә Кадыйр кызы.**



Дәү әнием Кукмара районының Торыш авылында 1930 елның уналтынчы февралендә икенче бала булып дөньяга килә. Ул бик акыллы, шук кыз булып үсә. Дәү әнием Сәрдекбаш мәктәбендә 4 ел белем ала. Сугыш башланганда аңа 11 яшь кенә тулган була. Сугыш башлангач тормыш бик авыр була. Олылар һәм балалар көне-төне ару-талуны белми эшлиләр.

Дәү әнием Шәмәрдән станциясендә товар поездына ягар өчен утын әзерләгән. Олылар агачларны кисеп, ярып, ә балалар ярган агачларны штабельгә өеп торган. Колхозда бәрәңге утыртканда да дәү әнием читтә йөрми, ул ат башы тотып йөрүче булып эшли. Иген уңмаган еллар да була. Ул вакытта чәчкән борчакны, арпаны кул белән йолкыганнар.

Дәү әниемнең абыйсын 18 яше тулган көнне үк сугышка алып китәләр. Аны Арзамаста алты ай укытканнар. Ул сугышта 3 тапкыр яралана һәм 1943нче елның 30 нчы маенда соңгы хаты килә. Дәү әнием колхозда төрле эшләрдә эшли, аларга сайланып утырырга мөмкинлек булмый.

# Шарипова Асия Вафа кызы



Минем дәү әнием Шарипова Асия Вафа кызы 1930 елның 2 октябрендә Дөбьяз районы Чыршы авылында крестьян гаиләсендә туган. Авылындагы мәктәптә дүрт класс бетергән.

Бөек Ватан сугышы башланганда дәү әнигә унбер яшь булган. “Кыенлыктан, авырлыктан чыгу юлларын олылар белән бергә без дә эзләдек. Сугыш елларында колхоздагы авыр эшләрне балаларга эшләргә туры килде. Кикәри дә җыйдык, көтү дә көттек, урман кистек, яшелчәдә эшләдек, арыш, бодай да үстердек”, - ди ул.

Әйе, тормыш йөген ат урынына җигелеп тартырга туры килә аңарга. Үз язмышыннан зарланмыйча, гомерен хезмәттә үткәрә ул.

Дәү әниемнең әтисе Вафа сугышка китә һәм исән-сау әйләнеп кайта.

Дәү әнием белән дәү әтием биш бала тәрбияләп үстерәләр: Мәгъсүм, Зөләйха, Марсель, Альберт, Гөлнара. Балалары да үзләре кебек тырыш, эшчәннәр, тормышта үз юлларын тапканнар.

Дәү әнием бүгенге көндә дә очкын кебек: бакчасында төрле җимешләр үстерә, күп итеп кайнатмалар ясый, күпереп торган бәлешләр пешерә, якты йөзе, кайнар чәе белән безне каршы ала.



Дәү әниемнең “Ветеран Великой Отечественной войны” кенәгәсе, Ана медале һәм бик күп Мактау грамоталары бар. Мин аның белән горурланам!

Дәү әниемә мин саулык-сәламәтлек, рух ныклыгы, балалар, оныклар бәхете телим. Күңеле һәрвакыт шулай яшь булып калсын!

***Оныгы Залалиева Эльмира.***
***2014 ел.***

# Шәйхетдинова Әлфия Шәйхи кызы

Шәйхетдинова Әлфия Шәйхи кызы 1935 нче елның 15 нче сентябрендә Кече Рәс авылында туа. Сугыш башланганда 5 яше дә тулмаган кыз була. Аяз, матур көннәрнең берсендә урамда балалар җыелып “Аяк” уены уйныйлар. Атка утырган кешеләрнең елый-елый китеп барганнарын күреп аптыраштa калалар. Бу Бөек Ватан сугышы башланган көн була.Балалар өйләренә таралышалар. Әлфия апаның әтисе сугышка алына. Елый-елый әтисен сугышка озатканын нәни булса да бүгенгедәй хәтерли ул. “Без әнигә биш бала калдык. Беркем дә булышмады. Тормышлар авыр якка үзгәрде. Ашарга юк. Үлән белән тукландык. Шулай да ачтан үлмәдек. Әни тырышлыгы аркасында сугыш авырлыгын җиңеп чыга алдык. Әни көне буе колхоз эшендә булды. Аның белән мин дә ияреп бара идем. Хәлемнән килгәнчә булышырга тырыша идем. Ул вакытта хатын-кызлар сугышчыларга оекбашлар, бияләйләр бәйләп җибәрә иде. Әтинең көн дә хатын көттек. Әлегә исән дип язылган хатларына куана-куана укый идек”.

Сугыш беткәнен урамда кычкырып йөриләр. Бар да шатлана, бар да елый. Әлфия апаның әтисе Гәрәфетдин исән – сау әйләнеп кайта. Сугышта аның кулы яралана. Ул кайткач дөнья түгәрәкләнә. Әнисе белән әтисе сугыштан соң да эшләп яшиләр.

Әлфия апа Кече Рәс мәктәбендә 7 класс белем ала. Шуннан аның хезмәт стажы башлана. Хатын-кыз булуына карамастан ул гомер буе, 60 яшенә кадәр тракторчы булып эшли. Эшләү дәверендә Хезмәт Кызыл байрагы ордены белән бүләкләнә. Мактау грамоталарын санап бетерерлек түгел. Пенсиягә киткәндә аңа гомер буе тырышып эшләгәне өчен үзе эшләгән тракторын бүләк итеп бирәләр. Бүгенге көндә ул хезмәт ветераны булып дөнья көтеп яши. Яшь буын сугыш афәтен күрмәсен дип изге теләкләрен теләп безне озатып калды.

**Шәйхетдинова Зөһрә**
**5 нче сыйныф укучылары**

# Шигабиев Габделәхәт Абдуллаҗан улы



Шигабиев Габделәхәт Абдуллаҗан улы 1937 нче елның 5 мартында Суксу авылында туа. 1946 елны гына Суксу җидееллык мәктәбенә укырга керә. Мәктәп 2 этажлы була. Ташсу, Чәмәк, Кондырлы, Рәс, Зур Рәс балалары 4 нче класска киләләр. "380 бала идек"- дип сөйли ул. А, Б, В, класслары да бар иде. 2 шәр сменада укыйлар. Ул вакытта комсомоллар колхозга бик булышты".

Сугыш башланганын "Колхозчы" район газетасыннан беләләр. 1941 нче елның 22 июнендә 18 яшьтән алып 60 яшькә кадәр булган барлык ир-атлар алына. Дөбъяз военкоматына әтисен 1942 елда алалар. Аннан аларны Казан татвоенкоматына җибәрәләр. Шуннан сугышка. Әтисеннән 4 бала: Каюм, Габделхай, Илсун һәм Әхәт абый кала.

Бик авыр була ул вакытта авыл халкына. Сугыш чорында күп хатын-кызларны окоп казырга җибәрәләр. Бөтен әйберне сугышка: бәрәңге, ит, кимендә 40 кг., йомырка, оекбашлар җибәрәләр. Сугыш башланган елны иген уңмый. Бәксәрдән бәрәңге, кәбестә, кыяр алып кайталар. 10-12 яшьлек балалар уракка чыгалар. Әхәт абый да басуда башак җыярга булыша. Урып-җыю чорында кайбер аналар балаларын җәлләп башак алып кайталар. Әгәр тотылсалар, берничә башак өчен төрмәгә утыртканнар, штраф салганнар. Нишләсеннәр, ашарга кирәк. Колхоз акча бирми. Азрак бәрәңге утыртканнар, ул да күпкә җитмәгән.

Төннәрен әнисе, Ашам абый, Шакир абый, Минхаҗ абыйлар утын урларга менәләр. Менмәсләр иде, өйне җылытырга кирәк.

Сугыш авырлыгын күтәрергә беркем дә ярдәм итми. Үз көчләре белән булдыра алганча халык бер-берсенә ярдәм итеп итеп яшиләр һәм эшлиләр.

Әхәт абый Сугыш беткәнен Дөбъяз радиосыннан белә. Ул вакытта Һәр көнне Дөбъязга ипигә менәргә кирәк булган,ул талон буенча гына бирелгән, озын чиратларда торып кичләрен генә төшә торган булган. Җиңү шатлыгын шунда менгәч, Дөбьяз радиосыннан белгән. Әтисе 1947 елда исән - сау әйләнеп кайта.

1955 елга кадәр алар авырлык белән яшиләр. "55-56 елларда гына чын ипине беренче тапкыр ашадык. Шуннан бәрәңге була башлагач, аны кабартма, ипи итеп пешерә идек. 60 елларда туйганчы ашый башладык"- дип әрнеп сөйли ул.

Сугыш вакытында шатлыклы мизгелләр дә була. "Сыер маена Бәксәрдән әни чабата алып кайтты. Яңа чабата, башмак кию зур бәхет иде. Шулай ук бәрәңге, он булганда умач итеп сөт белән пешерү. Кычытканнан, кыргый кливер, бәрәңге сабыннан пешерелгән аш ашаган балаларга мондый ризык ашау, бер бәйрәм булган.

Әхәт абый гомер буе җитәкче урыннарда:партком председателе, китапханә мөдире, авыл советы рәисе булып эшли. Эшләү дәверендә таләпчәнлеге, җаваплылыгы, кайгыртучанлыгы, кешелекле булуы белән дан казана. Авыл халкы аны әле дә хөрмәт итеп яши. Эшләгән дәвердә алган бүләкләре санап бетергесез.

Тормыш иптәше Филсинә апа белән мактап туймаслык 3 бала тәрбияләп үстергәннәр. Кызганыч, уртанчы уллары – менә дигән егет, армиядән кайткач, суга батып үлә. Бала ачысы татырга туры килә. Шуңа да аларның теләкләре: беркемгә дә Ходай-тәгалә бала ачысысын күрсәтмәсен, балалар әти-әниләрен тыңласыннар, сау-сәламәт булсыннар. Башка сугышлар була күрмәсен!

## Шигабиева Сания Газиз кызы



Шигабиева Сания Газиз кызы 1924 елның 10 нчы октябрендә Дөбъяз районы, Рәс авылында туган. Айбаш авылында 4 класс белем ала. Латынча укый. Кечкенәдән урак ура, атлы машиналарда көлтә бәйли, көрәк белән казып бәрәңге утырталар, шулай ук ат сызган буразналарга бәрәңге салып торалар. Ашарга сугышка кадәр җитәрлек була. Колхоз ипиен, бәрәңгесен биреп тора.

1941 нче ел. Барлык эшкә яраклы халык көлтә бәйли, кемнәрдер фермада эштә була. Кемдер басуга килеп "Сугыш башланган"- дип кычкыра. "Барыбыз да елаша-елаша авылга чаптык" -дип сөйли Сания апа.

Шуннан инде авылдан берәм-берәм ир-егетләрне сугышка ала башлыйлар. Икенче агымга Сания апаның да әтисен дә алалар. Әнисе 3 бала белән ялгызы кала. Менә шуннан соң инде чын-чынлап авыр тормыш башлана. Барлык хезмәт хатын-кызлар, карт-карчыклар, балалар җилкәсенә кала. Сания апага сугыш башланган да 17 яшь була. Ул көндезләрен олылар белән беррәттән көлтә бәйли, төнлә атлы машинада ашлык суга. Шуның өчен колхоз 0,5 кг. ипи бирә. Моның белән генә эш төгәлләнми. 1942 нче елны яшь кызларны Арча кырына, кирпеч заводына эшкә җибәрәләр. Анда еш кына тревогалар булып тора. "Сугыш Мәскәүгә килеп җитә"-дигән хәбәр килгәч, заводны ябалар. Эшкә килгәннәр яңадан авылга кайталар. Кайталар да эшкә керешәләр. 1943 елның июнендә яшь кызларны яңадан ФЗО га төзелешкә эшкә җибәрәләр. Анда җимерек биналарны төзекләндерүдә булышалар. Бер ел эшли яшь кыз төзелештә. Ашарга юньләп юк, киярге кием дә тузган, ямаулы. Шулай булса да түзәләр, чөнки максатлары бер: фашистларны туган илебездән куып чыгару. Кар астыннан черек бәрәңге казып ашаганнарын әле дә әрнеп сөйли ул.

1944 елда комбайнер булып эшли башлый. Язын бәрәңге чүпләүдә, яруда катнаша. 1945 елның 9 маенда шул ук подвалда бәрәңге чүпләп утырганда "Сугыш беткән!"-дигән шатлыклы хәбәр кереп кычкыралар. Бар халык шатланып өйләренә тарала. Бар да туганнарын, якыннарын көтеп яши башлый..

Сания апаларга нәкъ Җиңү көнне-9 майда әтисенең үле хәбәре турындагы кара кәгазьне китерәләр. "Әти менә тиздән кайтыр"-дигән өметләре чәлпәрәмә килә.

1948 нче елда Суыксу авылына сугыштан кайткан Кашаф исемле егеткә кияүгә чыга. Колхозда эшли башлый: симәнә чыгара. Көннәр буе елгадан ташып атларга су эчерәләр, черек бәрәңге чүплиләр. Шуннан 30 ел дәвамында бозаулар карый. Гомуми эш стажы - 68 ел. Кашаф абый белән 57 ел гомер итә. Һәр кешегә үрнәк гаилә булып яшиләр. Хәзерге көндә ул "Хезмәт ветераны", "Сугыш ветераны" таныклыгына ия. Бик күп мактау кәгазьләре, рәхмәт хатлары иясе.

**Сәйфуллин Булат, 3 нче сыйныф**

## Шигабиева Филсинә Хисмәтулла кызы

Бөек Ватан сугышы беткәнгә инде ничә еллар авышса да, сугыш вакытында кайгы-хәсрәт китергән көннәр берничек тә онытыла торган түгел. Бу авырлыкны шул чорга туры килгән сугыш чоры балаларына да күтәрергә туры килгән. Нәни сабыйларның әниләре кочагында иркәләнеп ятырга мөмкинлекләре булмаган. Көн-төн колхоз кырларында эшләгән әниләренең балаларны яратып утырырга җайлары чыкмаган шул. Ул еллардагы сабыйларның балалык елларын бәхетле дип әйтеп булмый. Шушы сабыйларның берсе – минем дәү әнием - Шигабиева Филсинә Хисмәтулловна 1940 елның 13 нче гыйнварында Биектау районы Суксу авылында туган. Сугыш башланганда 6 айлык булган. Сугыш вакытында әнисе колхозда нинди эш булган, хәленнән килгәнчә анда эшләгән. Әтисе сугышка китеп, кире әйләнеп кайтмаган. Сугыш дәү әниемне ятим иткән. 7 ел Суксу мәктәбендә белем алган. Укып бетергәч колхозда табельщица булып 2 ел . Аннары фермада учетчица булып урнаша. Авыл советында җыештыручы булып та эшли. Соңрак озак еллар дәвамында склад мөдире булып колхозда эшләгән. Дәү әтием Габделхәй белән 4 бала тәрбияләп үстергәннәр. Мактау кәгазьләре юк, ләкин миллионлаган рәхмәт сүзләре күп. Хәзерге көндә безнең янәшәдә бәхетле гомер кичерә. Көн саен безне: “Исән-сау йөрегез” - дип мәктәпкә, эшкә озатып кала.

## Шигабиев Габдулхай Абдулла улы

Дәү әтием Шигабиев Габдулхай Абдуллович та сугыш чоры баласы. Ул 1935 нче елның 26 январендә Суксу авылында туган. Сугыш башланганда 6 яшьтә булган. “Сугыш вакытында ат башы тотып йөрдек”, - дип сөйләде. Кеп – кечкенә балалар ничек итеп эшләгәннәрен күз алдына китерүе дә кыен. Ашарларына да юньләп булмаган, кигән киемнәре дә ямаулы булган. Рәхәтләнеп уйнар вакытларын эштә авыштырганнар. Балалык еллары бөтенләй булмаган. Әтисе сугышка барып исән - сау кире әйләнеп кайткан. Иң бәхетле мизгел - шул вакыт булган дәү әтием өчен. 7 ел Суксу башлангыч мәктәбендә укыган. 1955 елдан алып 1995 нче елга кадәр электрик-монтер булып эшләгән. Эшләү дәверендә мактау кәгазьләре белән бүләкләнгән.

**Шигабиева Зөһрә**
**8 нче сыйныф укучысы**